• КЫЙССА •
ӘЮБ ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ
5 бит

• САБЫЙГА •
КОРЪӘННЕҢ ҖӨЗЛӘРЕ
9 бит

• ҮРНӘК ЗАТЛАР•
ГАБДЕЛХАК ХӘЛФӘ ТУРЫНДА ХӘТЕР ЯҢАРТАБЫЗ
12-13 битләр

• ӘДӘБИ СӘХИФӘ •
КАЙНАР ДИҢГЕЗ ЮЛЫ
14 бит

*№ 1 (306)* *Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы* *җөмәдәл-ахыр 1442*

*Гыйнвар, 2021*

# دين ومعيشت
# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

## Онлайн татар мәдрәсәсе ишекләрен ачты

**medrese.tatar**

*Туган тел елын йомгаклап һәм Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын каршылап, Татарстан мөфтияте һәм аның карамагында эшчәнлек алып бара торган “Хозур” нәшрият йорты тиңе булмаган зур яңа проект – татар телендә беренче онлайн-мәдрәсә булдырды.*

*Дәвамы 8 нче биттә*

# Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына бурычлар билгеләнде

***14 нче гыйнварда Казанның Галиев мәчетендә нәзарәтнең Аксакаллар шурасы утырышы узды. Чараны шура әгъзасы, Яшел Үзән районы имам-мөхтәсибе Габделхәмит хәзрәт Зиннәтуллин Коръән аятьләре укып башлады, Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин дога кылды. Утырышны Аксакаллар шурасы рәисе Айрат хәзрәт Җәюпов алып барды. Ул беренче чиратта Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы башланганын билгеләп үтте, ТР Президенты каршындагы татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясенә рәхмәтләрен җиткерде, әлеге комиссиядә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның әгъза булып торуын искә төшерде.***

Алга таба сүз Аксакаллар шурасы тарафыннан 2021 елда – Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы кысаларында бурычлар һәм тормышка ашырырга ниятләнгән планнар буенча фикер алышу хакында барды. Утырышта Казанда татар-мөселман мәктәбен булдыру, яшь буынга рухи-әхлакый тәрбия бирү, күп телләр өйрәнүгә мәхәббәт тәрбияләү, эш сөючән һәм булдыклы татар улкызларын тәрбияләү мәсьәләләре күтәрелде. Күренекле татар галиме, тарихчы Индус Таһиров нәзарәтнең мәчет каршындагы курсларын да ислам дине нигезләрен татар телен өйрәтү дәресләре белән бергә алып бару башлангычын хуплады һәм аны милләт өчен бик кирәкле эш дип бәяләде. “Әгәр дә татарлар революциягә кадәр Рәсәйнең укымышлы халкы булган икән, моңа безнең динебез, мәдрәсәләребез, муллаларыбыз сәбәпче, чөнки уку-укыту көчле булган, һәрбер авылда кызларны һәм малайларны аерым укыткannar, мәчет һәм мәдрәсәләр эшләгән”, – дип, ул татар теле дәресләре, вәгазьләр уку, борынгы китапларны өйрәнү, саклау тәҗрибәсен дәвам итәргә чакырды.

Аксакаллар шурасы әгъзалары мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә нәзарәтнең туган телебезне үстерү юлына басуын билгеләп, киләчәктә тагын да нәтиҗәлерәк эшләү буенча тәкъдимнәре белән бүлештеләр.

Аксакаллар шурасының Мөслим районы вәкиле Расих хәзрәт Каюмов халык санын алу кампаниясендә җиң сызганып эшләргә чакырды: “Безгә, татарларга, халык санын алу алдыннан тарихи китаплар бастырырга, халыкның үзаңын күтәрергә кирәк”, – диде ул һәм халык белән ныграк аралашырга кирәклеген әйтте.

Аксакаллар шурасы рәисе урынбасары Мансур хәзрәт Җәләлетдинов балаларга телне өйрәнүгә кызыксыну тудыру өчен чараларны һәм мөмкинлекләрне көчәйтергә кирәклеккә басым ясады. “Хәзерге балаларны китапка тартырга кирәк. Алар телефонда мультфильмнар, видеороликлар карап утыра. Татар телле контентны үстерүгә үз өлешебезне кертсәк иде. Бу – конкрет тәкъдим”, – диде ул.

Очрашу ахырында Аксакаллар шурасы әгъзалары Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның татар телен саклау һәм үстерү буенча эшчәнлеген югары бәяләделәр һәм шура исеменнән аны киләсе срокка мөфти итеп сайларга тәкъдим иттеләр.

■ **dumrt.ru** сайтыннан

# Марат Әхмәтов мөфтияткә бүләкләр тапшырды




***14 нче гыйнварда ТР мөселманнары Диния нәзарәтендә ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, ТР Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин белән очрашты.***

Очрашуда шулай ук ТР Дәүләт Советының мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Айрат Ринат улы Зарипов та катнашты. Мөхтәрәм кунаклар мөфтияткә ТР Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү комиссиясе ярдәмендә нәшер ителгән “Татарча әлифба” һәм татар телендә сәнгатьле чыгыш ясарга өйрәтә торган ярдәмлек китапларын, шулай ук саллы тиражда бастырылган милли үзаң тәрбияләүгә юнәлтелгән эчтәлекле плакатлар һәм истәлекле түштамгалар тапшыру өчен килде.

Педагогика фәннәре кандидаты, ТР атказанган мәдәният хезмәткәре, Казан дәүләт мәдәният институты доценты, сәхнә теле һәм дикторлык осталыгы белгече Илсөяр Шиһапова һәм педагогика фәннәре кандидаты, Казан дәүләт мәдәният институты доценты, сәхнә теле белгече Земфира Ибәтованың “Чыгыш ясау сәнгате нигезләре һәм әдәби сөйләм (җитәкчеләр өчен практик кулланма)” китабы Татарстан имамнарына чыгыш ясау, үтемле вәгазь сөйләү осталыгын камилләштерү максатыннан, ярдәмче методик материал буларак бүләк ителде. Татарстан мәчетләренә тарату өчен, әлеге кулланма 1 мең данәдә тапшырылды.

Шагыйрә Фәйрүзә Мөслимованың “Татарча әлифба” балалар өчен шигырь китабы 5 мең данәдә чыгарылган. Ул мәчетләрдә яки имамны өйгә чакырып, балага исем куштырганда Исем кушу таныклыгы белән бергә биреләчәк. Мәчетләрдә һәм мәчет тирәләрендә урнаштыру өчен, ТР Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү комиссиясе шулай ук махсус плакатлар да булдырган. “Оныгың белән нинди телдә сөйләшәсең?” һәм Р.Фәйзуллинның “Нинди шатлык картлык көнеңдә – оныкларың сиңа рәхмәт әйтсә матур итеп туган телеңдә” сүзләре язылган плакатлар телне саклау һәм үстерү, халыкта милли үзаң тәрбияләү юнәлешендә хезмәт итәргә тиеш.

“И туган тел, и матур тел” дигән сүзләр язылган истәлекле түштамга һәм магнитлар, мәчетләрдә, мәдрәсәләрдә балалар өчен уздырыла торган чараларда тарату өчен, ясалган. «Үрнәк күрсәткән балаларны кызыксындыру өчен, аларга кечкенә генә бер истәлек булсын, дип тапшырсагыз иде», – диде Марат Әхмәтов.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин әлеге очрашуда мөфтият һәм ТР Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү комиссиясе белән милли мәсьәләргә карата уртак фикердә торуын билгеләп үтте һәм Марат Готыф улына үзе дә истәлекле бүләк — Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы уңаеннан ТР мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан чыгарылган календарь тапшырды. Әлеге календарьда танылган татар дин әһелләренең һәм җәмәгать эшлеклеләренең туган телне – татар телен саклауга кагылышлы канатлы гыйбарәләре бирелгән. Моннан тыш, Камил хәзрәт Марат Готыф улына Исламны кабул итүгә 1100-еллык уңаеннан махсус чыгарылган һәм «Динсез милләт булмый» дигән язулы өс киеме бүләк итте.

Марат Әхмәтов очрашу ахырында алга таба да бер фикердә, бер-береңә кирәк булып һәм бер максатны күз алдында тотып яшәргә һәм эшләргә чакырды. “Дине булса, теле дә саклана, теле булса, дине дә саклана”, – диде ул. Мөфти дә хуплап: “Милләт динебезне саклый, динебез милләтебезне саклый”, – дип зур рәхмәт әйтте.

■ **dumrt.ru** сайтыннан

# БИАда Гамәлгә куючылар советы утырышы узды



15 нче гыйнварда Болгар ислам академиясенең Гамәлгә куючылар советы утырышы узды.

Киңәшмә академияне гамәлгә куючылар Советы рәисе, Татарстан мөфтие урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов җитәкчелегендә һәм Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашында үтте. Шулай ук утырыш эшенә интернет аша Башкортстан Республикасы мөселманнарының төбәк Диния нәзарәте рәисе, Рәсәй мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте администрациясе җитәкчесе, мөфти Мөхәммәд хәзрәт Таҗетдин, Рәсәй Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте рәисе урынбасары, Мәскәү өлкәсе мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Рушан хәзрәт Аббясов кушылды. Моннан тыш, утырышта академиянең фәнни эшчәнлек буенча проректоры Айнур Тимерханов та бар иде.

Утырыш Камил хәзрәт Сәмигуллинның Коръән аятьләрен уку һәм дога кылу белән башланып китте. Аннары көн тәртибенең төп соравы – Болгар ислам академиясе ректоры вазифаларын башкаручыны билгеләү мәсьәләсе каралды. Белем бирү оешмасы Уставы нигезендә Гамәлгә куючылар советы әгъзалары әлеге функцияләрне академиянең фәнни эшчәнлек буенча проректоры Айнур Тимерхановка тапшырырга тәкъдим иттеләр. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча аның кандидатурасы бертавыштан кабул ителде. Утырышта катнашучылар Болгар ислам академиясенең яңа җитәкчесенә уңышлар теләде.

Моннан тыш, киңәшмәдә катнашучылар 2019 елдан югары уку йортын җитәкләгән элекке ректор Данияр Абдрахмановка намуслы хезмәте өчен рәхмәтләрен һәм аның тәҗрибәсе Рәсәйнең башка фәнни-белем бирү оешмаларында уңышлы файдаланыуна өметләрен белдерделәр, шулай ук БИА үсешендә дәвамчылыкны саклауның мөһимлеген ассызыкладылар.

Айнур Тимерханов академиянең Гамәлгә куючылар советы тарафыннан үзенә күрсәтелгән ышанычы өчен рәхмәтен әйтте. “Минем кандидатураны Болгар ислам академиясе ректоры вазифаларын башкаручы итеп хуплавыгыз өчен сезгә рәхмәтемне белдерәм. Минем өчен Ислам уку йортын җитәкләү – зур дәрәҗә һәм шул ук вакытта зур җаваплылык. Билгеле булганча, Болгар ислам академиясе Рәсәй ислам мәгариф системасының югары баскычын били. Шуңа күрә Академия алдында Рәсәй һәм якын чит ил күләмендә зур бурыч тора: Рәсәй мөселманнарының дини һәм рухи мирасын торгызу һәм алга таба үстерү, шулай ук ислам мәгарифе системасын күтәрү. ИншәАллаһ, уртак тырышлык белән без бу һәм башка мәсьәләләрне уңышлы хәл итүдә алга китә алачакбыз», – диде Айнур Тимерханов.

Утырышны Илфар хәзрәт Хәсәнов дога кылып төгәлләде.

■ **dumrt.ru** сайтыннан

# Нәзарәт мөселман яшьләренең кышкы форумын башлап җибәрде

***20 нчы гыйнварда Казанда XI Мөселман яшьләре форумы ачылды, ул Рәсәйнең төрле почмакларыннан 120 егет һәм кызны җыйды. Быелгы кышкы форум ике мәйданчыкта – егетләр һәм кызлар өчен аерым узуы белән үзенчәлекле.***

Әлеге форумның темасы “Нәфес һәм йөрәкнең рухи авырулары” дип билгеләнгән. Егетләргә дүрт көн дәвамында РИИ мөгаллиме, гакыйдә, хәнәфи фикһы буенча китаплар һәм мәкаләләр авторы Әхмәд Әбү Яхъя Әл-Хәнәфи, танылган мөгаллим Зәкәрия хәзрәт Тимганов белем бирсә, кызларга күренекле абыстай Мәрьям Зәбирова остазлык кылачак. Дүрт көн дәвамында форумда катнашучылар йөрәк белән бәйле 3 рухи «авыру» (рия, гафләт, ачу һәм көнләшү) хакында фикер алышачак һәм аларны «дәвалау» юлларын өйрәнәчәк.

Мөселман яшьләренең рәсәйкүләм слетына Мәскәү, Казан, Уфа, Пенза, Пермь, Ульяновск, Самара шәһәрләреннән, Чиләбе өлкәсе, Марий-Эль Республикасы вәкилләре һәм Татарстан районнарыннан катнашучылар килде. Аларның барысына да 18 яшьтән 30 яшькә кадәр. Оештыручылар тарафыннан коронавирус һәм сулыш юллары инфекциясе таралуны булдырмый калу максатыннан, барлык саклык чаралары күрелде: катнашучылар өчен җитәрлек күләмдә медицина битлекләре, антисептиклар һәм башка гигиена әйберләре әзерләнде.

Кызлар турыдан-туры Казанның Заречье лагерена килеп урнашса, егетләр башта нәзарәткә җыелып, аннары Болгарга кузгалып китте. Алар беренче чиратта дүрт көнлек форумның программасы, куркынычсызлык кагыйдәләре белән танышты, иртәнге намаз укыды һәм догалар укып эшкә кереште.

Буадан 25 яшьлек Руслан Нотфуллин, форумны сагынып, быелгы чарага өченче ел рәттән килгән. 2020 елның кышкы һәм җәйге форумнарында аңа аеруча остазлар белән дәресләр, аларга турыдан-туры сораулар бирү мөмкинлеге булу ошаган. Ул яшьләр җыенын оештыру дәрәҗәсен югары бәяләде, программага спорт чараларын күбрәк өстәргә тәкъдим итте, киләчәктә футбол турнирын күрергә теләвен җиткерде.

Ә менә Түбән Камадан килгән 22 яшьлек Кәрим Хәсәнов кышкы форумда беренче тапкыр катнаша. Ул мөхтәсибәттә яшьләр бүлеге җитәкчесе булып хезмәт иткәнлектән, форумны оештыруга, биредәге тәртипкә зур әһәмият биреп килгән. Ул: “Минем өчен бу форумга катнашучыларны туплау, алар белән элемтә булдыру, программа төзү, остазлар билгеләү, дәресләр расписаниесен төзү һ.б. кызыклы. Аралашу, остазларның лекцияләре, мастер-класслар – барысы да җәйге форумда бик кызыклы узды. Кыш көне дә ачык һавада чаралар узар дип уйлыйм. Үзем өчен иң мөһиме итеп Болгар ислам академиясендәге мохитне тою, белем туплаучылар белән янәшә утырып, дүрт көн генә булса да мөмкин кадәр күбрәк белем үзләштереп калуны саныйм», – диде. Анысы, форумның темасы бүгенге көннең иң актуаль мәсьәләләрен ача. Егетләр һәм кызларның аерым булуы, калеб (күңел) белән бәйле рухи авыруларны өйрәнгәндә, күпкә уңайлы.

Форумда катнашучыларны лекцияләр тыңладылар, "бау" квестлары, шулай ук тимбилдинг уздылар. Бу форумда катнашучыларга бердәм команда булырга ярдәм итте. Укудан тыш, яшьләр өчен 3 ял итү мәйданчыгы әзерләнгән иде: кинозал, чаңгыда йөрү зонасы, шулай ук теләүчеләр остазлар белән сорау-җавап форматында аралаша алдылар. Гадәттәгечә, яшьләр социаль челтәрләрдә мавыктыргыч конкурсларда да катнаштылар.

Шунысы мөһим: форум яшьләргә белемнәрен ныгытырга гына түгел, шулай ук берләшергә, танышырга, рухи яктан баерга һәм үзләренең социаль башлангычларын тормышка ашырырга мөмкинлек бирде.

■ **dumrt.ru** сайтыннан

# «Коръән – рухи азык»

*Узган санда ТҖ МДНнең Шәригать сораулары бүлегенең баш белгече, Коръәнне өйрәнү үзәгенең җитәкчесе, Коръән-хафиз Илнур хәзрәт Хәйруллин белән Аллаһының Изге Китабы булган Коръән, аны ятлауның фазыйләтләре хакында әңгәмә корган идек. Бүгенге санда сезгә шушы әңгәмәнең дәвамын тәкъдим итәбез.*



**– Казанда Коръән ятлау үзәкләре бар. Алар ничегрәк һәм нинди система белән эшлиләр?**

– Мәчетләр каршында эшләп килгән якшәмбе курсларыннан кала, Казанда Коръән ятлау буенча ике зур үзәк бар. Аларның берсе – Рәсәй Ислам институтына бәйле булган "Рәшидә" үзәге. Икенчесе – "Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә инде күп еллардан бирле эшләп килә торган Коръән ятлау үзәге. Ләкин хәзерге вакытта, мәдрәсәдә яңарту эшләре алып бару сәбәпле, әлегә "Галиев" мәчетендә ятлыйлар.

**– Шушы үзәкләргә керергә теләгән кешеләргә нинди таләпләр куела? Алар гарәп телен белергә тиешме, әллә күпмедер дәрәҗәдә Коръәнне инде яттан белүе шартмы?**

– Без иң элек керүчеләрнең санына карыйбыз. Мәсәлән, "Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә Коръән-хафизлар өчен билгеләнгән аерым урыннар исәбе бар. Әгәр укырга теләүчеләрнең саны бик күп булса, алар имтихан аша кабул ителә. Яшь категориясе дә исәпкә алына, ягъни 9 нчы сыйныфны тәмамлап, кулында аттестат булса, ул укырга керә ала. Ләкин бер шарты бар: ким дигәндә, Коръәннән берничә сүрәне укый белергә тиеш. Әйткәнемчә, укырга керергә теләүчеләрнең саны күп булган очракта, без аларның имтиханнар тапшыру нәтиҗәләренә һәм тел белүләренә игътибар итәбез. Килүчеләр арасында телне белмәүчеләр дә еш очрый, аларга тәҗвид яки гарәп телен укыту шактый авыр. Укулар рус телендә алып барылганга, укырга керүчеләр Рәсәй тарихы һәм рус теле фәне буенча имтиханнар тапшыра.

**– Ятлаган Коръәнне онытмас өчен нишләргә кирәк?**

– Коръәнне ятлау белән генә эш тәмамланмый. Кеше аның белән гамәл дә кылырга тиеш. Әгәр ул аятьне белә икән, шуның белән гамәл кылса, ул аны онытмый. Әгәр инде кеше Коръәнне ятласа, ләкин гарәп телен белмәсә, Коръәнне ятлап бетергәч, гарәп телен өйрәнү бу кешегә вәҗиб хөкемендә була. Хәрәкәләрне бутамас өчен дә гарәп телен белү кирәк. Кеше хәрәкәләрне бутап, сүзнең мәгънәсен үзгәртә. Гарәп телен белү Коръәнне аңлауны да җиңеләйтә. Аллаһы Тәгалә Үзе үк: "Бу Коръән турында кешеләр фикерләмәсләрмени?" – дип әйтә. Безнең максат – укып, фикерләп, шуның белән яшәү. Ә инде онытмас өчен, һәрдаим кабатлап торырга кирәк, чөнки күп хәдисләрдә Коръән бик тиз кача дип килә. Әгәр дөяләрнең аякларын бәйләп куеп, аларны озак карамый торсаң, алар шул бауларын чишеп качалар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә Коръән ятлауны шуның белән чагыштыра, ягъни гел кабатлап тормасаң, Коръән дә кача. Шуңа да, онытмау өчен, гел кабатлап тору кирәк. Коръән-хафизга, ким дигәндә, көненә 20 бит кабатлап тору кирәк. Бу бигрәк тә Коръәнне яңа гына ятлап бетергән Коръән-хафизларга кагыла. Ә инде Коръәнне кабатлап торган кеше күпмедер вакыт кабатламый торса да, ул аңа зур зыян китерми. Коръән-хафизлар өчен иң яхшы кабатлау – Рамазан аенда тәравихта Коръәнне хәтем кылу, чөнки Рамазан аенда бик җиңел. Аллаһы Тәгалә Үзе җиңеллек бирә. Тәҗрибәдән дә күргән бар: әгәр кеше 3-4 ел дәвамында шулай Рамазан аенда Коръәнне хәтем чыкса, ягъни Коръәнне тулысынча укыса, ул аны онытмый.

**– Гарәп телен белгән һәм гарәп телен белмәгән кешеләр өчен Коръәнне ятлау нинди фазыйләтләр бирә?**

– Әгәр кеше Коръәнне ятласа, Коръән бу кешенең йөрәгендә була, ягъни ул – Коръәнне йөртүче. Ул кешедән Коръәнне беркем дә тартып ала алмый. Коръән белән Аллаһы Тәгалә бу кешегә хикмәт, сәламәтлек, бәрәкәт бирә. Бу бәрәкәт аның киемендә дә, ризыгында да чагылыш таба. Коръәнне гел кабатлап тору хәтерне яхшыртуга да тәэсир итә. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк: Коръән әле кешене саклый да. Төрле бәлаләрдән, күз тиюләрдән, бозыклыклардан саклый. Болар барысы да – бу дөньядагы фазыйләтләр. Коръән ятлауның Ахирәт тормышында фазыйләтләре дә бик күп. Бу турыда хәдисләрдә дә әйтелә. Мәсәлән, бер хәдистә болай дип әйтелгән: "Фани дөньяда Коръәнне ничек укыган булсаң, Ахирәт тормышында да укы, чөнки һәр укыган аять белән кешенең дәрәҗәсе күтәреләчәк". Җәннәтнең дәрәҗәләре нәкъ менә Коръән аятьләренә тиң. Без җәннәтнең 8 дәрәҗәсе бар икәнен беләбез, ләкин бу дәрәҗәләр әле үз эчләрендә күп төрләргә бүленәләр. Аларның барысын да санап чыгарсак, Коръән аятьләренә туры килә. Кеше, Коръәнне күбрәк ятлаган саен, югары дәрәҗәләргә күтәреләчәк, иншәАллаһ. Тагын бер хәдистә болай дип килә. Әгәр Коръән-хафиз Коръәнне укып, аның буенча яшәсә, мөэмин булган, ләкин нинди дер гөнаһлары сәбәпле җәһәннәмгә керергә тиешле булган 10 (ә икенче бер риваятьтә – 7) туганын, Аллаһының рөхсәте белән, шәфәгатьчелек кылып, үзе артыннан җәннәткә алып керә алачак. Бу да бик зур фазыйләт, минемчә, чөнки бу туганнары үзләре иманлы, ләкин гөнаһлары бик күп һәм, шул сәбәпле, җәһәннәмгә керергә тиеш булырлар иде. Әгәр бер туганы яки балаларының берсе Коръәнне ятлаган булса, ул аларны җәннәткә алып керә алачак. Җәһәннәмнән котылу – бик зур нигъмәт ул. Шулай ук Коръәннең аерым сүрәләрен ятлауның фазыйләтләре хакында да хәдисләр бар. Мәсәлән, "Кем "Әл-Бәкара" сүрәсен еш укып (хәдистә «укыса» дип килә) торса, Кыямәт көнендә бу сүрә ул кеше өчен болыт кебек булыр һәм гөнаһларыннан шәфәгать кылыр". Икенче бер хәдистә болай дип килә: "Кем бу дөньяда бик еш "Әл-Бәкара" һәм "Әлү Гыймран" сүрәләрен укыса, алар ике болыт шикелле килер. Бу ике болытның araларында нур булыр һәм укыган кешегә шәфәгать кылырлар".

**– Илнур хәзрәт, хәдистә әйтелгән мондый сүзләр бар: "Коръән – синең өчен яки сиңа каршы дәлил". Моны ничек аңларга? Ничек инде Коръән сиңа каршы дәлил булырга мөмкин?**

– Коръәндә безгә Аллаһы Тәгалә Үз кануннарын да әйтә. Әгәр кеше Коръән укып, шул кануннар буенча яшәсә, Коръән синең өчен, ягъни синең яклы дәлил була. Әгәр инде син укып та, укыганнарга каршы килсәң, кануннарга буйсынмый яшәсәң, Коръән инде бу очракта сиңа каршы дәлил булачак.

**– Гакыйдә фәне буенча кабер газабы хакында беләбез. Ялгышмасам, бер хәдистә көн саен "Әл-Мульк" сүрәсен уку шул кабер газабыннан котылуның бер сәбәбе булып тора дип килә. Бу сүрәне кайчан укырга кирәк?**

– Хәдисләрдән ястү намазыннан соң һәм ахшам намазыннан соң, дип ишеткәнем бар. Шәхсән үзем ястү намазыннан соң укырга тырышам. Хәдистә әйтелә: "Кем төнлә белән "Әл-Мульк" сүрәсен укыса, бу сүрә, бу кабер кешене газапламасын өчен, җиңгәнче көрәшер". Монда бер шарт бар: көн саен, ягъни бер көн дә калдырмыйча укырга кирәк. Тагын бер хәдистә "Әл-Мульк" һәм "Әс-Сәҗдә" сүрәләрен бергә укыса дип килә.

**– Илнур хәзрәт, редакциябезгә килеп, эчтәлекле һәм файдалы мәгълүмат биргегез, әңгәмәгез өчен Аллаһының рәхмәте булсын. Алга таба да сезне үзебезнең редакциябездә кунакта көтеп калабыз һәм киләсе әңгәмәләрдә аерым сүрәләрнең, аятьләрнең фазыйләтләре хакында сөйләшербез, иншәАллаһ. Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!**

– Вә галәйкүм әссәләм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

■ Әңгәмәне **Ленар ХАММАТОВ** оештырды

# Әюб галәйһиссәлам кыйссасы

*Әюб галәйһиссәлам чын диндар кеше сыйфатларын һәм хакыйкый сабырлык үрнәкләрен үзендә гәүдәләндергән, исәпсез-хисапсыз байлыкларга ия булган. Аңа караган җирләрнең – чиге, ә көтүлекләрнең саны булмаган. Әмма иң кадерле байлыгы булып күпсанлы балалары торган.*



Шул ук вакытта Әюб галәйһиссәлам үзенең кешелекле булуы һәм юмартлыгы белән аерылып торган. Ул үз байлыгын Аллаһы риза булырлык эшләр өчен тотып, барысына – тол хатыннарга яки ятимнәргә, хәерчеләргә киң күңел белән ярдәм иткән. Шул рәвешле Әюб галәйһиссәлам үзенең Раббысына рәхмәтен белдергән һәм Аңа көндезләрен һәм төннәрен гыйбадәт кылган. Аның намазлары ихласлылык һәм Аллаһыга мәхәббәт белән сугарылган булган. Яратучы Зат Үзе үк Әюб галәйһиссәламнең сабырлыгын мактаган! Шуңа күрә җирдәге һәм күктәге фәрештәләр аңа кунакка килгәннәр һәм аңа изге дога кылганнар.

Әмма иблисне көнчелек хисе биләп алган. Ул пәйгамбәрнең юлдан язуын, буйсынучанлык күрсәтмәвен һәм Аллаһының рәхмәтеннән колак кагуын теләгән. Бервакыт ул Аллаһыга шундый үтенеч белән мөрәҗәгать иткән:

– Ий Аллаһы! Әюб бик күп гыйбадәт кыла, әмма теләсә нинди башка кол да, шундый ук байлыклар бирелсә, гыйбадәтләрне кылыр иде. Ул Сине бүләк ителгән игелекләр өчен мактый. Әмма, әгәр дә Син аңа афәтләр җибәрсәң һәм әлеге байлыклардан аерсаң, аның хакыйкый ниятләре ачык күренәчәк, һәм ул Сиңа каршы килә башлаячак.

Шулай итеп, иблис Аллаһы Тәгаләгә Әюб галәйһиссәламнең ихласлыгын сынарга тәкъдим иткән. Моңа рөхсәт алып, ул үзенә барлык гыйфритләрне (җеннәрне) җыйган һәм аларга Әюб галәйһиссәламнең барлык мал-мөлкәтен таларга яки юкка чыгарырга һәм аны туры юлдан яздырырга әмер биргән. Ул чагында күктән ут ява башлаган һәм ул ут Әюб галәйһиссәламгә караган барлык көтүлекләрне көтүчеләре белән бергә юк иткән. Шуннан соң шәйтан, бер көтүче кыяфәтенә кереп, күз яшьләре белән Әюб галәйһиссәламгә килгән:

– Күрәсеңме, синең Раббың нәрсә эшләде? Синең барлык көтүлекләрең көтүчеләре белән бергә янды, алар көлгә әйләнде. Бары миңа берүземә генә котылу насыйп булды.

Әюб галәйһиссәлам бар сабырлыгын учына җыеп, Аллаһыга тәвәккәллек кылып болай дип әйткән:

– Күңелсезләнмә! Миндә булган барлык мал-мөлкәтне һәм байлыкны миңа Раббым бирде. Хәзер Ул аларның барысын да алды. Ул – Хак Хуҗа, теләгән вакытта – бүләкли, теләгән чагында – кире ала.

Боларны әйтеп, Әюб галәйһиссәлам гыйбадәт кылуын дәвам иткән. Мәлгунь шәйтан Әюб галәйһиссәламгә шакката һәм кырын эшен ахырына җиткерергә теләп, аның җирләренә, бакчаларына һәм чәчүлекләренә дә зыян китерергә уйлый. Алар барысы да көчле давыллар һәм су басулар белән юкка чыгарыла. Игенче кыяфәтенә кереп, шәйтан янә Әюб галәйһиссәлам янына килә. Беренче мәртәбә килгәндә күргән кебек, ул аны гыйбадәт кылган хәлдә очрата һәм такмаклап еларга тотына, әмма тагын шул ук җавапны ишетә.

Шәйтанның тырышлыклары икенче килүендә дә, аннары да уңыш белән тәгәлләнми. Зур югалтуларга да карамастан, Әюб галәйһиссәлам үз Раббысын зикер кылуны дәвам иткән, үзенең язмышына риза булып ныклык һәм сабырлык күрсәткән. Шәйтанның көнчелеге һәм үче тагын да көчәйгән. Ул янә Аллаһыга мөрәҗәгать иткән:

– Ий Аллаһы! Аның барлык мал-мөлкәте һәм байлыгы юкка чыгарылды, әмма аның барлык балалары да исән, димәк анда юкка чыгарылганны кабаттан кайтару өмете яши. Әгәр аны балалары белән сынасаң, Син аның сабырлыгы һәм буйсынучанлыгы ихлас булмавын күрерсең.

Аллаһы Тәгалә шәйтанга боларны эшләргә дә рөхсәт биргән. Мәлгунь шәйтан җил-давыл чакырган һәм Әюб галәйһиссәламнең балалары яшәгән йортларны җимерткән. Алар барысы да җимерекләр астында калып үлгәннәр.

– Ий Әюб! Күрәсең, кылган гыйбадәтләрең синең Раббың өчен берни дә түгел икән, – дип котырта башлый. – Кара, Ул сиңа ничек ачуланган!

Үз балаларын кызганып, Әюб галәйһиссәлам еларга тотынган. Моны күреп, шайтан шатланган, әмма шул мизгелдә Әюб галәйһиссәлам болай дип әйткән:

– Минем балаларымны дөньяга җибәрүче – Аллаһы. Ул – аларга тормыш бүләк иткән, һәм Ул – тормыштан мәхрүм итүче. Барлык карарлар да бары Аллаһы Тәгаләнеке генә. Ул – Бирүче һәм Ул – Алучы.

Шәйтанның ярсуының, котырынуының чиге булмый: нинди иман, нинди сабырлык, нинди тәвәккәллек соң бу!!! Һәм ул янә Әюб галәйһиссәламне авыру белән сынау өчен Аллаһыга мөрәҗәгать иткән. Аллаһы Тәгалә янә рөхсәт биргән. Әмма Әюб галәйһиссәламнең теленә, йөрәгенә һәм акылына кагылуны тыйган. Шәйтанга монысы да җитәрлек булган. Һәм бервакыт, Әюб галәйһиссәлам гыйбадәт кылганда, сәҗдә вакытында шәйтан аның борынына өргән. Әлеге утка охшаш ләгънәтле сулышны алганнан соң, ул Әюб тәненең барлык өлешләренә дә үтеп кергән. Аның башыннан, күзеннән, теленнән һәм йөрәгеннән кала бар тәне яралар һәм эренле шешләр (үлекләр) белән капланган, ул шешәргә һәм кычытырга тотынган… Көннән-көн Әюб галәйһиссәламнең авыруы көчәйгән.

Якыннары һәм туганнары, хәтта аңа иман китерүчеләр дә, аны ташлап киткәннәр. Янында бары сөекле хатыны Рәхимә генә калган. Ул Әюб галәйһиссәламне бер мизгелгә дә калдырып китмәгән һәм, ирен дәвалау өчен, кулыннан килгәннең барын да эшләгән. Ә бервакыт Рәхимә Әюб галәйһиссәламнән, саулык-сәламәтлеккә ирешү өчен, дога кылырга сораган. Әюб галәйһиссәлам болай дип әйткән:

– Мин иминлектә һәм сәламәт хәлдә ничә ел яшәдем?

– Сиксән ел.

– Ә бу авыру белән мин ничә ел яшәдем?

– Җиде (яки унҗиде) ел.

– Мин иминлектә, рәхәтлектә ничә ел яшәгән булсам, шул ук гомерне авыру хәлемдә дә сабыр итеп үткәрергә, аннары гына шифа сорарга тиешмен.

Авыру артканнан арта барган һәм Әюб галәйһиссәламне шәһәрдән куып чыгарганнар. Кешеләргә күрсәтми генә хатыны Рәхимә аны үз аркасына салып күтәреп чыккан. Башкалар Әюб галәйһиссәламнән йөз чөерсәләр дә, хатыны Рәхимә иреннән баш тартмаган, булдыра алганча аны тәрбия кылган. Әюб галәйһиссәлам, бик авыр хәлдә булуына карамастан, үзенең бар вакытын Аллаһыны зикер итүгә багышлаган. Иртән Рәхимә ризык эзләп шәһәргә китә торган булган, беркем дә аны эшкә алмаган. Аннары, яшәр өчен бернинди мал-мөлкәтсез калганнан соң, төшенкелеккә бирелеп, ул үзенең озын һәм куе чәчләрен кискән һәм аларны бай гаиләдә яшәүче бер кызга саткан.

■ **Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН,**
Татарстан Республикасы мөфтие

*(Дәвамы киләсе санда)*

# Аллаһы Тәгалә барлыкка китергәннәрнең хикмәте

*Барлык галәмнәрнең Раббысы булган, безне Үзенең төрле нигъмәтләре белән нигъмәтләгән Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед һәм сәналәр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең Хәбибе һәм Хак расүле, галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.*



***«Ий кешеләр! Сезне бер җаннан [Адәмнән] яраткан, аның бер кисәгеннән [булган сул кабыргасының иң астыннан Хавва исемле] ишен яраткан һәм аларның икесеннән бик күп ирләр белән хатыннарны халык кылып [җиһанга] тараткан Раббыгыздан куркыгыз. Аның исеме белән бер-берегездән үтенә торган Аллаһыдан [Аңа каршы баш күтәрүдән] һәм туганлык җепләреннән [аларның өзелүеннән] куркыгыз. Һичшиксез, Аллаһы – сезне күзәтүче».***

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:1

Бер мизгелгә уйланып алыгыз әле: нинди гүзәл бу дөнья! Күпме матурлык анда! Карагыз әле, безнең Җир шарында нинди мәһабәт таулар, иксез-чиксез далалар яки урманнар, джунглилар, тирән һәм әле дә өйрәнелеп бетмәгән диңгез-океаннар бар.

Әлбәттә, иманлы адәм баласы боларның барлыкка китерүчесе Аллаһы Тәгалә икәнен таный. Танымаслык түгел бит: Җир шары, Кояш йолдызы, еракгагы калган йолдызлар, без белмәгән планеталар, гомумән, җиһан, көн-төн, акылга ия кеше, су, һава, ут – болар барысы да Аллаһы Тәгаләнең зур аятьләре булып тормыйлармы соң?

***"Ий кешеләр! Сезне дә, сездән әүвәлгеләрне дә Яратучы Раббыгызга гыйбадәт кылыгыз, бәлки, [Аллаһының газабыннан үзегезне коткарып] саклана алырсыз. Ул [Раббыгыз] җирне – сезнең [җәйләп урнаша алуыгыз] өчен түшәк, күкне [биек түбә һәм гөмбәз кебек] бина итте, күктән су иңдерде һәм, аның белән сезгә ризык булсын өчен, [туфрактан] төрле җимешләр чыгарды. Сез, белгән хәлдә, Аллаһыга һичнәрсәне тиң итеп куймагыз".***

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:21-22

***«Аллаһы – җиде [кат] күкне Яратучы һәм шуның кадәр үк җирне дә [бар итүче]. Аллаһының – һәрнәрсәгә [көче җиткән] кодрәтле икәнен һәм Аллаһының гыйлеме белән һәрнәрсәне уратып алганын белүегез өчен, әмер [каза һәм кадәрдән гыйбарәт булган бар итү һәм идарә итү эше] алар [җиде кат күк белән җиде кат җир катлары] арасында иңеп тора".***

«Әт-Талак», 65:12

Яхшырак аңлар өчен, бер-ике мисал карыйк:

Аллаһы Тәгалә безнең өчен ризык яраткан. Аллаһы Тәгалә нинди генә агач, шул агачларда нинди генә җимешләр барлыкка китермәгән. Җир шары буенча нинди генә үсемлекләр, хайваннар юк. Хак Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

***«Ул – кайсына атланып йөрүегез, кайсын [итен] ашавыгыз өчен сезгә терлек-туарны Яратучы».***

«Гафир / Гафу итүче», 40:79

Шулай ук үләннәр һәм үсемлекләр турында Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

***"Үләннәр һәм агачлар [яратылган максатка хезмәт итү өчен, Яратучыларына] сәҗдә кылалар".***

«Әр-Рахмән / Мәрхәмәтле», 55:6

Чыннан да, үләннәр һәм үсемлекләрнең вазифаларын санап бетергесез. Алар – безгә, хайваннарга ризык, сулар өчен, кислород чыгаручы да, кош-кортлар өчен оя да. Һәм әле без белми торган күпме сыйфатлары бардыр.

Бу аятьтән күренгәнчә, Аллаһы Тәгаләнең барлыкка китергән нәрсәләре Аңа гел гыйбадәттә, сәҗдәдә икән. Кадерле җәмәгать, без дә Аллаһы Тәгаләнең мәхлүкъләры, без дә бит гел гыйбадәттә булырга тиешбездер: күп итеп зикер кылырга, намазлар укырга, садакалар бирергә һ.б.

Шулай ук Аллаһы Тәгалә бу дөньяны бер системага салып яраткан.

"Йәсин" сүрәсен исегезгә төшерсәгез, Аллаһы Тәгалә ай, кояшның үз юллары буенча йөрүләре, аларның үз вазифалары барлыгы турында әйтә. Аларның шулай йөрүеннән, Җир шарының үз тирәли һәм Кояш тирәли әйләнүеннән көн һәм төн, ел фасыллары барлыкка килә дә.

Көн һәм төннең дә үз вазифасы бар.

***"Аллаһы – сезгә, [ял итеп] тынычлык табуыгыз өчен, төнне [караңгылык итеп] Яратучы, көнне исә – [эшләп кәсеп итү, ихтыяҗларыгызны күрүгез өчен] яктылык итеп [бар итүче]. Һичшиксез, Аллаһы кешеләргә карата [ирешелмәслек дәрәҗәдә зур] рәхмәт [һәм чиксез игелек] Иясе. Ләкин кешеләрнең күбесе шөкер итмиләр".***

«Гафир / Гафу итүче», 40:61

"Ән-Нәбә" сүрәсендә дә Раббыбыз моның турында безгә искә төшерә. Чыннан да, бер төн эчендә күпме сихәт бар бит, арып-талып эштән кайткач, инде бер дә хәл калмаган кебек тоела. Әмма иртән инде Аллаһы Тәгалә шушы төн эчендә безгә күпме ял биргән була.

Кадерле җәмәгать, Аллаһы Тәгаләнең барлыкка китергән әйберләреннән күпме гыйбрәт, хикмәт табып була. Ә иң мөһиме, барлык мәхлүкат Аллаһыга мохтаҗ икәнен онытмасак иде. Аллаһы Тәгалә Үзенең мәхлүкъларына мохтаҗ түгел, киресенчә, Ул – "Әс-Самәде", ягъни бөтен барлык Аңа мохтаҗ. Бер генә мизгелгә дә Аның рәхмәтеннән башка яши алмый. Каты таш та, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте булмаса, тузан кебек коелып бетәр иде.

***"Аллаһы – һәрнәрсәнең Яратучысы. Ул – һәрнәрсәгә Яклаучы. [Шуңа күрә бөтен барлыклар бар булуларында Аңа мохтаҗ булганнары кебек, яшәүләрен дәвам итүләре өчен дә Аңа мохтаҗлар]".***

«Әз-Зүмәр / Төркемнәр», 39:62

Инде вәгазебезнең ахырында шуны әйтәсе килә: Раббыбыз безне бу дөньяда да камил итеп яратты, әмма онытмыйк, безнең әле Ахирәт дөньябыз бар. Раббыбыз болай дип әйтә:

***"Күкләр белән җирне Яратучы алар шикелләләрне [яңадан] яратырга кодрәтле түгелме әллә? Әйе! [Әлбәттә, Аның һәрнәрсәгә көче җитә!] Ул бит [мәхлүкъләры бик күп булган һәм кабат-кабат] Яратучы, [һәрнәрсәне] Белүче".***

"Йәсин", 36:81

Көн саен Раббыбызның барлыкка китергәннәренә карап, фикерләп, Аңа якынаерга насыйп булса иде. Әмин!

■ **Шамил хәзрәт ӘХМӘТГАЛИЕВ,**
Хәсәншәех авылы мәчете имам-хатыйбы

# Газраил һәм адәм баласының үлеме

Берьюлы Газраил галәйһиссәлам Сөләйман галәйһиссәлам янына килгән. Күпмедер вакыттан соң ул Сөләйман галәйһиссәлам янында торган кешегә текәлеп карап тора башлаган. Теге кеше аның күз карашын сизеп, Сөләйман галәйһиссәламнән:

– Бу кем? – дип сораган.

Пәйгамбәр:

– Бу – Газраил, – дип җавап биргән.

Бу кеше:

– Мөгаен, ул минем җанымны алырга телидер. Җилгә мине Һиндстанга илтеп куярга әмер ит, – дип әйткән.

Сөләйман галәйһиссәлам аның үтенечен башкарганнан соң, Газраилдән нигә бу кешегә шулай карап торганын сораган. Ул:

– Миңа бу кешенең җанын Һиндстанда вакытта алырга кушылган иде. Әмма аны синең яныңда күреп гаҗәпләндем, шуңа да текәлеп карап тордым, – дип җавап биргән.

**Нәсыйхәт:**

Кеше кайда гына булмасын, үлем аңа киләчәк. Коръәндә:

**"Һәр җан иясе үлемне татыячак"**, – дип язылган.

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:35

# Нур белән тулы кул

Әгърифләр солтаны Бәязид Бистами рахимәһуллаһи болай дип сөйләгән: "Берьюлы төнлә мин Аллаһыга дога белән ялвардым. Бер кулымны җиңемнән чыгардым, әмма бик салкын булганга күрә, икенчесен чыгарып тормадым. Шуннан соң мин йокыга киттем. Һәм төшемдә догага күтәрелгән кулым нур белән тулганын, ә икенчесе буш калганын күрдем. Мин Аллаһыдан:

– Йә Аллаһым! Нигә минем икенче кулым буш? – дип сорадым.

Ул:

– Без догага күтәрелгән кулыңны нур белән тутырдык. Ә күтәрелмәгән кулыңны без нурдан мәхрүм калдырдык", – дип әйтте.

**Нәсыйхәт:**

Кешегә никадәр генә авыр булса да, ул гыйбадәтен кылырга тиеш. Аллаһыга гыйбадәт кылу зур нигъмәт булып тора. Мөэмин кеше: "Мин бу гыйбадәтләрне башкармаучылар саныннан да була ала идем, әмма Аллаһыга шөкер, мин аларны үтим", – дип әйтергә тиеш.

Дога вакытында кулларны күтәрергә кирәк. Бу безнең догаларыбызның кабул булуына тәэсир ясый. Сәлман Әл-Фәрсидән ирештерелгән хәдистә болай дип әйтелгән: "Сезнең Раббыгыз – юмартлык һәм тыйнаклык иясе. Коллары кулларын күтәреп дога кылганда, ул аларны буш калдырырга ояла".

# Нәфескә хисап тоту

Әмер Әл-Бүннәни рахимәһуллаһи болай дип сөйләгән: "Берьюлы мин кабердә утырган бер дәрвишне күрдем. Аның уң кулында ак ташлар, ә сул кулында кара ташлар иде. Мин:

– Йә дәрвиш! Син монда нишлисең? – дип сорадым.

Ул:

– Вакыт-вакыт каберләргә килеп, мин монда ятучы мәетләрдән дәрес алам, – дип әйткән.

Мин аннан:

– Кулларында нинди ташлар? Алар нәрсәгә кирәк? – дип сорадым.

Ул:

– Мин изге гамәл кылгач, ак ташны карасына өстим, ә гөнаһ кылсам, кара ташны аклары янына куям. Кич җиткәч ташларны саныйм. Әгәр бу көнне изгелекләрем, гөнаһларыма караганда күбрәк булса, ифтар кылып, гыйбадәтемә керешәм. Әгәр изгелекләремә караганда гөнаһларым күбрәк булса, ул кичне бернәрсә дә ашамыйм һәм эчмим. Минем халәтем шундый", – дип җавап бирде.

**Нәсыйхәт:**

Һәр кичне кеше үткәргән көне өчен үз-үзе алдында хисап тотарга тиеш. Гомәр радыяллаһу ганһе: "Хисап тотарга чакырылганчы үз-үзегез алдында хисап тотыгыз", – дип әйткән.

Безгә хәтле яшәгән кайбер кешеләр "Гамәлләр көндәлеге" алып барганнар. Көн дәвамында анда яхшы һәм яман гамәлләрен язып барганнар, ә кич җиткәч үз-үзләре алдында хисап тотканнар.

**"Рухуль Бәйан"** китабыннан

# Дәшмәвең – алтын

*"Кыямәт көненә ышанган кеше
хәерле сүз генә сөйләсен яки дәшмәсен"*

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әлеге сүзләре һәрберебез өчен дә бер үгет-нәсыйхәт, хәтта кисәтү булып тора. Бу хәдис һәр заман өчен дә актуаль. Кайвакытта уйламыйча яки уйлап, әмма кызган баштан әйтелгән сүзләр йокысыз төннәрнең, борчулы көннәрнең сәбәпчесе буларга мөмкин. Хикмәт иясләре: "Авыздагы сүзгә син ия, авыздан чыккач, сүз ия", – дигәннәр.

Без мәгълүмат дөньясында яшибез. Һәрдаим кемнең кая барганын, ниләр эшләгәнен белеп торабыз. Бүген газета-журналлар, телевидение һәм радиога өстәп, социаль челтәрләр дә үз эшен башкара: кешене төрле кирәкмәгән уйлар, фаразлар белән "баетып" кына тора. Хәер, аннан башка да мөмкин түгел, билгеле. Тик еш кына вакытны файдалы үткәрергә, кирәкле мәгълүмат алырга теләгәндә нәкъ менә шушы "челтәрләр"дә "эләгеп" калабыз. Максатыбыз вакытны заяга үткәрү булмаса да, кадерле, санаулы минутларыбызны телефон тотып үткәрүгә сарыф иткәнне сизми дә калабыз.

**Үзеңә кагылмаганнан ерак тор**

Расүлебез: "Кешенең Ислам динен күркәм рәвештә тотуының бер билгесе: аның үзенә кагылмаган нәрсәләрдән баш тартуы", – дип әйткән (имам Әт-Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан).

Бу хәдис бигрәк тә бүгенге көн өчен актуаль. Мәгълүмат дөньясында кайнаганда безгә бернинди дә катышы булмаган, алар турында белү-белмәү безгә бернинди дә зыян да, файда да китермәгән кешеләрнең тормышларын тикшерү, җитмәсә, белмичә аларның адресларына төрле кирәкмәгән сүзләр язудан, гаепләүләрдән ерак булсак иде. Беренчедән, бу безгә кагылмый. Икенчедән, без алар хакында бернәрсә дә белмибез, чөнки имеш-мимешләр, фаразлар ул хакыйкать дигән сүз түгел. Бер хикмәт иясе, кемнедер гаепләр алдыннан, аның аяк киемен киеп, ул йөргән юлны үтеп кара, дигән. Без бер яссылыктан гына күрәбез. Ә чынлыкта, бу кеше турында без белмәгән, күрмәгән, аңламаган, хәтта күз алдына да китерә алмаган фактлар бар. Әгәр аларны белгән булсак, безнең фикеребез башка төрле булыр иде.

Әйе, Расүлебезнең: "Яманлык күрсәгез, кулыгыз белән туктатыгыз, кулыгыз белән туктата алмасасыз, телегез белән, алай да булдыра алмасагыз, йөрәгегез белән риза булмагыз. Әмма бу – ихласлыкның иң түбән дәрәҗәсе", – дигән хәдисе бар. Тик бу хәдис башка очракка карый. Мәсәлән, берәүнең, бигрәк тә, сезнең сүзегез үтә торган берәр якыныгызның килешсез ягын күрсәгез, аңа нәсыйхәт әйтү, күркәм киңәшләр бирү гаеп түгел, билгеле. Монда да үз тәртипләре бар. Бу нәсыйхәтләрне әйтү кеше янында үзеңне күрсәтү, акыллы булып тоелу максатын алга куярга тиеш түгел. Ниятегез ул кешегә дөреслекне күрсәтү булсын.


Һәрбер сүзне әйтер, ә социаль челтәрләрдә "үз фикеребезне" калдырыр алдыннан, әйткәннәребез, язганнарыбыз өчен бу дөньяда җавап бирмәсәк тә, һичшиксез, Ахирәт дөньясында җавап тотарга тиеш булуыбызны хәтердән чыгармасак иде.

■ Айсылу ЮЛДАШЕВА



# Беренче онлайн-мәдрәсә ишекләрен ачты

***Туган тел елын йомгаклап һәм Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын каршылап, Татарстан мөфтияте һәм аның карамагында эшчәнлек алып бара торган “Хозур” нәшрият йорты тиңе булмаган зур яңа проект – татар телендә беренче онлайн-мәдрәсә булдырды.***




Бу проект 20 нче гыйнварда тәүге тапкыр журналистларга тәкъдим ителде. Шулай итеп, планетабызның төрле почмакларында яшәүче милләттәшләребезнең туган телдә Ислам нигезләре буенча гыйлем алу мөмкинлеге барлыкка килде. Моннан тыш, уникаль гыйлем мәйданчыгы Татарстанда ислам мәгарифенең беренче баскычын – мәчет каршындагы курсларын да сыйфат ягыннан яңа югары дәрәҗәгә күтәрде. Онлайн-мәдрәсә мәчетләре булмаган яисә мәчет каршындагы курслар оештырылмаган җирлекләрдә яшәүче татарларга яки вакыты аз булган милләттәшләргә дини белем алырга ярдәм итәчәк. Онлайн-мәдрәсә medrese.tatar адресы буенча урнашкан белем бирү платформасында эшли. Мәдрәсәдә шулай ук iOS һәм Android базасындагы смартфоннар өчен эшләнгән махсус кушымта аша да “кереп” укып булачак. “Татар мәдрәсәсе” дип исемләнгән мобиль кушымтаны кесә телефонына Play Маркет һәм App Store-да бушлай күчереп алырга мөмкин.

Татар онлайн-мәдрәсәсендә дәресләрне видео, текст һәм аудио форматларында үзеңә уңайлы урында, тәүлегенә 24 сәгать дәвамында интернетка тоташкан теләсә кайсы җайланмадан (компьютер, планшет, смартфон һ.б.) үзләштерергә мөмкин. Оештыручылар иң беренче чиратта хәзерге заманда мәгълүмат алуның иң кулай һәм җайлы форматы булган видеодәресләргә төп игътибар юнәлтте. “Мәдрәсә” өчен барлыгы 7 дисциплина – ислам хокукы (фикһ), гакыйдә, Коръән һәм тәфсир, ислам әхлагы, гарәп теле һәм тәҗвид, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормыш юлы (сирасы) һәм татарларда Ислам тарихы – буенча 124 видеодәрес яздырылды. Аларның һәрберсе якынча 15 минутлык озынлыкта. Онлайн-мәдрәсәдәге контент Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан мәчет каршындагы курслар өчен эшләнгән һәм кабул ителгән уку-укыту программасы нигезендә гамәлгә ашырылды.

Аерым алганда, лекцияләрнең эчтәлекләре нәзарәтнең методистлары тарафыннан төзелде һәм төп методик әсбап сыйфатында “Ислам дине нигезләре” китабы файдаланылды. Ул Татарстан мәчетләрендә Ислам нигезләрен өйрәнү буенча курсларда төп дәреслек булып хезмәт итә. Видеолекцияләрнең кыскалыгы да тыңлаучыларга уку барышында игътибарны җуймыйча гыйлем эстәү мөмкинлеген бирәчәк. Моннан тыш, видео рәвешендәге мәгълүматны кабул итә алмаган “шәкертләр” өчен оештыручылар тарафыннан мәдрәсә сайтында һәр дәреснең текст форматы да урнаштырылды. Өстәмә рәвештә сайтта дәресләрнең аудиоверсияләре дә урын алды: видео карарга яисә текст укырга вакытлары булмаган дин кардәшләр мәгълүматны тыңлап үзләштерә алачак.

Medrese.tatar белем бирү платформасына барлык популяр социаль челтәрләр яисә электрон почта аша теркәлергә була. Системада теркәлгәннән соң, һәр укучыга шәхси кабинет ачыла. Биредә укучының үткән темалары, эшләгән тестлары һәм шәхси уңышлары турында мәгълүмат тупланачак. Онлайн-мәдрәсәдә “укучылар” һәр тема-дәрестән соң тикшерү тесты узарга тиеш булачак. Тестны уңышлы биргән очракта гына киләсе дәрескә күчеп була. Тест нәтиҗәләре түбән булган очракта “шәкерт” теманың үзләштерелмәгән яки авыр үзләштерелгән өлешенә кире кайта һәм кабаттан укырга тиеш булачак.

Онлайн-мәдрәсә остазлары итеп республикабызның югары дини уку йортларында гыйлем алган һәм Диния нәзарәтенең дини эшчәнлек алып барырга хокук бирүче Шәһадәтнамәсенә ия булган имамнар җәлеп ителде.

Нәзарәт тәкъдим иткән беренче татар онлайн-мәдрәсә проекты хәзерге вакытта интернеттагы билгесез "шәех"ләрнең лекцияләренә, шикле булган видеодәресләргә бердәнбер альтернатива булып тора.

■ **dumrt.ru** сайтыннан



# Коръәннең җөзләре



***Безнең Изге Китабыбыз Коръәни Кәрим, сүрә һәм аятьләрдән кала, җөз дип атала торган бүлекләрдән тора. Бу бүлекләр, Коръәнне уку уңайлы булсын өчен, хезмәт итә. Әйтик, Рамазан аенда көненә бер җөз укыган очракта, бер ай дәвамында Коръәнне укып чыгарга мөмкин.***

Изге Китабыбыз башыннан алып ахырына кадәр 30 өлешкә тигез итеп бүленгән. Һәм бу өлешне җөз дип атыйлар. Һәрбер җөз китап битенең кырыенда аерым бер тамга белән билгеләнгән. Төркиядә басылган Коръәннәрдә бу тамга роза чәчәге сыйфатында бирелә, ә башка илләрдә басылган Коръәннәрдә икенче төрле тамга кулланыла.

# Сүзләр очып таралыр, язылганнар калыр

***Безнең пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә аятьләр иңгәннән соң, ул аларны каләм тота белүче мөселманнарга язып барырга боерган. Коръәни Кәримне язып баручы кешеләрне "кәтибү вәхи" дип йөрткәннәр. Алар Расүлебездән ишеткән һәр аятьне язып барганнар. Бу кешеләр арасында әлеге сәхабәләр булган: Әбү Бәкер Әс-Ситдыйк, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб, Зәед бине Сабит радыяллаһу ганһүмә һәм башкалар. Коръән бернинди үзгәрешләрсез безнең көннәргә килеп җиткән.***

Безнең Пәйгамбәребездән соң Әбү Бәкер Әс-Ситдыйк мөселманнарның хәлифәсе булган. Ул идарә иткән елларда, Гомәр бине Хәттаб тәкъдиме белән, Коръән бер китап булып җыелган. Бу максатларны тормышка ашыруда Коръәнне яттан белүче кешеләр (Коръән-хафизлар) ярдәм иткән. Төрле битләргә язылган Коръәни Кәрим бергә тупланып, "Мөсхәф" дип аталган җыентыкны тәшкил иткән. Бу китап Әбү Бәкер радыяллаһу ганһедә үлеменә хәтле сакланган. Аннан Гомәр бине Хаттаб радыяллаһу ганһегә, ә аннан – аның кызы һәм расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хатыны Хафса радыяллаһу ганһәгә, ә аннан Госман бине Гаффан радыяллаһу ганһегә тапшырылган.

Госман бине Гаффан радыяллаһу ганһе идарә иткән елларда ислам дәүләте чикләре киңәя. Күпләр исламны кабул итә, мөселманнарның һәм мөселман җирләренең саны арта. Шул сәбәпле, Ислам дәүләтләренә Коръәннең бер нөсхәсен җибәрү ихтыяҗы туа. Һәм Коръәннең әлеге төп нөсхәсеннән бик күп Коръәннәр күчерелеп языла. Бу күчерелмәләр илнең иң зур җиде шәһәренә таратыла. Бүген өйләребездә булган Коръәни Кәрим нәкъ тә әлеге иң беренче Изге Китаптан күчереп язылган.

■ Сәхифәне **Айсылу ЮЛДАШЕВА** әзерләде

## «Хозур» нәшрият йорты
## Җәмалетдин Бикташиның «Фазаилеш-шөһүр яки савaплы гамәлләр» китабын нәшер итте

"Фазаилеш-шөһүр" – дини һәм әхлакый рухта булган китап. Әлеге китапта пәйгамбәрләр, сәхабәләр һәм әүлиялар тормышыннан алынган кыска кыйссалар, хикәятләр, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормыш юлыннан вакыйгалар белән беррәттән мөбарәк айларның, көннәрнең фазыйләтләре, дини гыйбарәләрнең үзенчәлекләре һәм савaплары хакында да бәян ителә.




**Китапны "Хозур" нәшрият йорты кибетләрендә сатып алырга һәм дистанцион рәвештә дә заказ бирергә мөмкин.**
**Кибет: Казан шәһ., Тукай ур., 36 нчы йорт.**
**Тел.: +7 960 072-74-63.**
**Склад: Казан шәһ., Газовая ур., 14 нче йорт.**
**Тел.: +7 (966) 250-00-09.**
**Интернет-кибет: huzurshop.ru.**

# Тәкәбберлек, масаючанлык

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә болай дип әйткән:

***«Без аңа: «Безнең күзәтүебез белән көймә яса. [Көймәгә утыру] Әмеребез килгәч һәм [Хавва радыяллаһу ганһәдән калган таш] мич [су ургылып һәм бик көчле итеп] кайнап чыккач, [суга батудан котылачак кешеләрнең һәрбереннән [анасы һәм атасы итеп] берәр пар һәм [мөселман булган хатының белән өч улыңның һәм аларның хатыннарыннан торган] гаиләңне аңа керт. Әмма [кяфер булган хатының, улың кебек] алар арасыннан [батып үләселәре турындагы] сүзем алдан әйтелгәннәрне түгел. Золым кылучылар хакында [догалар кылып] Миннән сорама. Һичшиксез, алар суга батырылачак»***

«Әл-Мүэминүн / Мөэминнәр», 23:27

***"Һичшиксез, Аллаһы аларның ачык эшләгәннәрен дә, яшерен эшләгәннәрен дә белә. [Шуңа күрә аларга лаек булган җәзаларын бирәчәк]. Һичшиксез, Ул тәкәбберләнүчеләрне сөйми";***

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:23

***"Әллә [инкяр итүчеләр] Мин мал һәм ир балалар бирәм дип уйлыйлармы?***

***Без аларны игелек белән нигъмәтләндерергә ашыгабыз [дип]? Юк шул! Белмиләр!"***

«Әл-Мөэминүн / Мөэминнәр», 23:55-56

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Бер кеше үз-үзенә масаеп, кигән киеме белән мактанып бара икән. Аллаһы Тәгалә җиргә аны йотарга әмер биргән һәм аның җиргә йотылуы Кыяматкәчә дәвам итәчәк» (Әл-Бохари, Китаб Әл-Либас, 5790; Әл-Мөслим, Китаб Әл-Либас, 2088; Ән-Нәсаи, Китаб-Уз-Зина, 8/206).

«Аллаһы Тәгалә залим һәм тәкәббер кешене Кыямәт көнендә вак кырмыскалар итеп кубарыр. Һәм аларны кешеләр таптап үтәрләр».

Элеккеге буын кешеләренең кайберләре тәкәбберлек – ул Аллаһы Тәгаләгә белдерелгән беренче «баш күтәрү», дип әйткәннәр.

Аллаһы Тәгалә болай дип әйткән:

***«Без фәрештәләргә [һәм җеннәргә]: «[Шәрәфен икърар итүегезне күрсәтү һәм аны сәламләү өчен] Адәмгә [кыйбла буларак юнәлеп] сәҗдә кылыгыз!» – дип әйткәч, алар [һәммәсе] сәҗдә кылдылар, бары Иблис [киреләнде, сәҗдәдән] баш тартты, тәкәбберләнде һәм кяферләрдән булды».***

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:34

Иблис кебек тәкәбберләнүченең иманыннан берниндидә файда булмас.

Расүлебез: «Тәкәбберлек – ул хакыйкатьне кабул итмәү һәм кешеләргә масаеп, өстән карау», – дип әйткән (Әл-Мөслим, Китаб Әл-Иман, 91).

Аллаһы Тәгалә болай дип әйткән:

***"[Тәкәбберләр кылган кебек] Йөзеңне кешеләрдән чөермә, җирдә масаеп йөрмә. Һичшиксез, Аллаһы һәр масаеп йөргән, үзен яратучы кешене сөйми [һәм аларның бу кыланышларыннан разый булмый]".***

«Локман», 31:18



Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аллаһы Тәгаләнең мондый сүзләр әйткәнлеген бәян итә: «Бөеклек – Минем киемем. Кодрәт – Минем япмам. Минем белән ярышырга теләүчене утка ташлаячакмын» (Әл-Мөслим, Китаб Әл-Бирр Вәсилә; Әбү Давыд, Китаб Әл-Либас, 4090).

Икенче бер хәдистә болай дип әйтелә: «Берьюлы җәннәт белән җәһәннәм үзара бәхәсләшә башлаган. Җәннәт: «Йә Раббым! Ни өчен миңа көчсезләр һәм зәгыйфьләр генә керә?» – дигән. Җәһәннәм: «Мин тәкәббер һәм гаделсез кешеләрнең урынына әверелдем», – дип белдергән» (Әл-Бохари, Китаб Әл-Тәфсир, 4850; Әл-Мөслим, Китаб Әл-Җәнаһ, 2846; Тирмизи, Китаб Әс-Сыйфатил Җәннәт, 2564).

Аллаһы Тәгалә болай дип әйткән:

***«Ул – [сиңа макталган] соңгы йорт. Без аны җирдә тәкәбберләнмәгән һәм бозыклык теләмәгәннәрнеке итәчәкбез. Ул [күркәм] нәтиҗә [әмерләрен тотып, тыюларыннан тыелып, Аллаһы Тәгаләнең газабыннан сакланган] тәкъвалык ияләренеке [булачак]».***

«Әл-Касас / Кыйсса», 28:83

Сәләмә бине Әл-Әквагъ болай дип сөйләгән:

«Берьюлы Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янында утыручы кеше сул кулы белән ашаган. Пәйгамбәребез аңа: «Уң кулың белән аша», – дип әйткән. Әлеге кеше: «Булдыра алмыйм», – дип җавап биргән». Аллаһы Расүле: «Ничек инде булдыра алмыйсың? Бары тәкәбберлек кенә аны мондый итә алды», – дип әйткән.

Һәм аның кулы башка күтәрелмәгән" (Әл-Мөслим, Китаб Әл-Әшриба, 2021).

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

«Җәһәннәм әһелләре турында беләсегез киләме? Алар – рәхимсез дошман, саран һәм тәкәбберләнүче», – дип әйткән (Әл-Бохари, 4918; Әл-Мөслим, Китабу Китаб Әс-Сыйфатил Җәннәт, 2853).

Ибне Гомәр радыяллаһу ганһе пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый сүзләрен риваять итә: «Аллаһы Тәгалә тәкәбберләнеп, үз-үзе белән масаеп йөрүче кешене ачулы халәттә каршы алачак».

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе болай дип әйткән:

«Тәмугка әлеге өч төркем кеше эләгәчәк: үзенең халкына зыян китерүче хаким, мал-мөлкәткә ия булып, аның белән тиешенчә эш итмәүче кеше, тәкәббер ярлы» (Хәким, Мүстәдрәк, 1/160).

Минемчә, тәкәбберлекнең иң югары дәрәҗәсе: гыйлемнәрең белән тәкәбберләнү һәм үзеңнең өстенлекләрең аркасында башкаларга карата тәкәббер мөнәсәбәттә булу. Андый кешегә булган гыйлемнәре бернинди дә файда китермәячәк. Ахирәт тормышы өчен туплаган гыйлемнәр кешене тыйнак итәр, йөрәген, нәфесен тынычландырыр һәм басынкы итәр, беркайчан да аны игътибарсыз калдырмас, бәлки, киресенчә, һәрдаим аны шелтәләп, дөресләп торыр. Әгәр ул моннан мәхрүм калса, юлыннан язар һәм һәлак булыр. Тәкәбберлекнең иң югары дәрәҗәсе: гыйлемне алган вакытта аны башка мөселманнарга тапшырганда тәкәбберлек күрсәтүне, аларның абруйларын киметүне максат итеп кую. Бу очракта әлеге хәдисне кагыйдә буларак китерү мөһим: «Күңелендә тамчы кадәр генә тәкәбберлек булса да, ул кеше җәннәткә кермәячәк» (Әбү Давыд, Китаб Әл-Әкзийә, 3599). Вә ләә хәүлә вә ләә куввәтә илләә билләһ.

■ **Имам Әз-Зәһәбинең «Әл-Кәбаир»** китабыннан

# Нәрсә соң ул гөнаһ?

***Гөнаһ – ул кешенең Ахирәттә газаплануына сәбәп булачак сүзләре, эшләре вә хәрәкәтләре.***

Ислам динендә гөнаһлар ике төрлегә аерыла. Беренчесе «гөнаһи кәбаир» (зур гөнаһлар) дип атала, икенчесенә «гөнаһи сәгаир» (кечкенә гөнаһлар) диелә.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтте:

***«Әгәр сез Аллаһы тарафыннан тыелган гөнаһларның зурларыннан саклансагыз, сездән кечкенә гөнаһларны да ерагайтырбыз һәм сезне шәрәфле бер урынга күтәрербез».***

«Ниса / Хатыннар», 4:31

Аллаһы Тәгалә кемнедер яки нәрсәнедер Үзенә тиң күрүдән башка бөтен гөнаһларны гафу итә ала. Әлбәттә, бу «барлык гөнаһлар да һичшиксез гафу ителер» дигән сүз түгел: һәр аерым очракта Аллаһы Тәгалә – Үзе хөкем кылучы. Аллаһы Тәгалә кешеләрнең гөнаһ эшләвен теләми. Кеше гөнаһ эшләгән булса, Ул аннан тәүбә көтәр. Әгәр кол, Аллаһыга ялварып, эшләгәннәренә үкенеп, киләчәктә ул хатаны эшләмәскә вәгъдә бирсә, Аллаһы каршында тәүбә итсә, иншәАллаһ, Җәнаби Хак Раббыбыз бу колын гафу итәр.

Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгалә шулай дигән:

***«Аллаһының рәхмәтеннән өметегезне өзмәгез, чөнки Аллаһы [ширектән тыш] барлык гөнаһларны да ярлыкый!» Һичшиксез, Ул – [гөнаһларны күпләп] Гафу итүче, Рәхимле».***

«Әз-Зүмәр / Төркемнәр», 39:53

■ **"Ислам дине нигезләре"** китабыннан



Хабибрахман Шакир:

# меңләгән күлләр иленә сикәлтәле юл

*Мәккәдәге кызлар өчен эшләгән беренче Коръән мәктәбенең татар имамы белән бәйле булуы*



**Фотода:**

*Хабибрахман Шакир хатынының абыйлары белән. Әфганстандагы 1930 еллар. Сулдан уңга утыручылар: Ришад (1910-1980), Хабибрахман Шакир (1903-1975), билгесез башкорт, Чиләбе мулласының улы. Сулдан уңга басып торучылар: Садид (1912-1999), Мотыйгулла (1917-1981), Нәсих (1915-2005).*

***Газетабызның алдагы санна-рында Тампере шәһәрендәге финнар җәмәгатьчелеге турында язган идек. Бу җәмәгатьчелекнең иң танылган кешеләренең берсе булып Хабибрахман Шакир (1903-1975) тора. Без аның кызыклы язмышына һәм эшчәнлегенә багышланган мәкаләләр циклын багышларга булдык.***

Хабибрахман Шакир шулай ук Хабибрахман Болгари исеме белән билгеле. Ул 1903 елда дөньяга килә. Төгәл кайсы җирдә туганы мәгълүм түгел. Әмма “Болгари” сүзенә караганда, аның Урта Идел буенда, Казан губерниясе җирлегендә туганлыгы аңлашыла. Тампере татар диаспорасы әһелләре аның, җәмәгатьчелекнең күпчелеге кебек, Түбән Новгород татар-мишәре булмавын, ә Казан татарлары арасыннан булуын билгеләп үтә.

Туган илендә башлангыч белемне алганнан соң, ул вакытта татарлардагы гадәт буенча, ул Бохарага китә. Ун ел дәвамында Бохара, Ташкент һәм Урта Азиянең башка күренекле ислам үзәкләрендә үзенең гыйлемнәрен камилләштерә. Ташкенттагы укулары вакытында ул Урта Азия һәм Казахстан мөселманнары Диния нәзарәтенең киләчәктә булачак икенче мөфтие **Зыятдин Бабахан (1908-1982)** белән таныша. Алар шактый еллар дустанә мөнәсәбәттә аралашып торалар. Хабибрахман Шакир бик гыйлемле кеше була. Туган теленнән тыш, ул гарәп, үзбәк, таҗик, төрек, урда һәм фарси телләрен дә белгән.

1917 елгы революция вакытында Хабибрахман Шакир Әфганстанга күченеп китәргә мәҗбүр була. Сүз уңаеннан, Әфганстан XX гасырның беренче яртысында алга киткән, шактый үсеш алган мөселман илләреннән була. Ул вакытта Кабул, совет хакимиятеннән качып килгән мөселманнар өчен бик тә мөһим эмиграция үзәге булып хезмәт итә. Әфганстан үзәгендә Хабибрахман Шакир танылган татар дин эшлеклесе **Шәмсулла Вәлиулла (1867-1930)** гаиләсе белән таныша. Бу танышу аның киләчәктәге тормышында зур роль уйный.

Шәмсулла хәзрәт Вәлиулла 1867 елны Иске Турай авылында (Башкортстанның хәзерге Йәрмәкәй районы) татар гаиләсендә туа. Дини гыйлемне авылларындагы мәдрәсәдә ала, Тукай һәм Түбән Бишинде авылларында мулла вазифасын үти. Революциягә кадәр Идел-Уралның күп кенә мәдрәсәләрендә дәрес бирә һәм дини сораулар буенча күп кенә китаплар яза. 1928 елда хакимияткә большевиклар килгәннән соң, гаиләсе белән Троицк шәһәренә сөргенгә җибәрелә. Элекккеге укучылары аны атып үтерелүгә дучар булудан коткарып кала. Соңрак ул гаиләсе белән яшерен рәвештә Урта Азиягә, ә аннары Әфганстанга качып китә. Шәмсулла хәзрәт үзенең гаиләсендә бары гарәп телендә генә сөйләшү гадәтен кертүе игътибарга лаек. Шуңа күрә дә аның барлык балалары кечкенәдән гарәп телен яхшы белгән.

1930 елда, 63 яшендә Шәмсулла хәзрәт Кабул шәһәрендә малярия авыруыннан вафат була. Аның зур гаиләсе: 9 улы һәм 3 кызы кала. Шуларның берсе – Бибирәйхана киләчәктә Хабибрахман Шакирның хәләл җефете була. Күпмедер вакыттан соң язмыш Шәмсулла хәзрәтнең гаиләсен бөтен дөнья буйлап тарата: уллары Садид (1912-1999) һәм Мотыйгулла (1917-1981) – Австралиядә, ә Ришад (1910-1980) Пакыстанда төпләнеп кала, Нәсих (1915-2005) исемле улы әниләре белән бергә Мәккәгә китә. Берникадәр вакытлардан соң, Шәмсулла хәзрәтнең бер кызы Бәбиджа Изге Мәккә шәһәрендә кызлар өчен беренче булган Коръән мәктәбенә нигез сала.

■ **Мөхсин НУРУЛЛА** язмасы, islam-today.ru сайтыннан тәрҗемә

*(Дәвамы киләсе санда)*

# Габделхак хәлфә турында хәтер яңартабыз

*Габделхак хәзрәт Каюмовның тууына 100 ел тулу уңаеннан*



**Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте баш мөфтие, Шәйхелислам Тәлгать хәзрәт Таҗетдин:**

"...Халык арасында "эшләпә Габделхак" дип йөртелгән хөрмәтле остазыбыз Габделхак абый Каюмов – бик тә ихлас, күптәннән белешә, йөрешә торган күркәм кардәшебез иде. Фронтовик, Ватан сугышында контузияләр алган, ә тыныч тормышта бик тә хәрәкәтле, тырыш, тәвәккәл абзый булды. Мәрҗани мәчете мөтәвәллиятенә кергәнче дә шыпырт кына динне өйрәтеп, укырга-язарга өйрәтеп, тәҗвид өйрәтеп ятты.

Безнең яшьлектә күңелләребезгә иман орлыклары салган, дин нигезләрен сеңдергән остазларның тагын бер бик күркәм гадәтләре бар иде. Алар шәкертләренә шушы дөньяны алып барырлык һөнәрләргә, тормыш көтү өчен кирәкле кәсепләргә дә бик тырышып өйрәттеләр. Габделхак абый Каюмовтан мин бүрек тегәргә өйрәндем. Бер көнне күрсәтте, икенче көнне оста өйрәткәнчә бүрекне тегеп, китереп күрсәттем. Бохарада укыган шәкерт чагымда каникулга Казанга кайткач, гел шул кәсептә булдым.

Габделхак остаз – тарих борылышларында яшәп, бәрәкәтле гомер кичергән, дин-исламыбызда зур урын тоткан, бик күп эшгамәлләргә өлгергән шәхес. Гомере буена ул халыкта Аллаһка, Аллаһның хак илчесенә, динебезгә мәхәббәт тәрбияләде".

**Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе мөдире, Казан шәһәренең "Ал" мәчет имам-хатыйбы Ильяс хәзрәт Җиһаншин:**

"...Дин өлкәсендә зур вазифаларга ирешмәсә дә, ул совет хакимияте елларында ук остаз-хәлфә бабай булып танылды. Габделхак абый дингә өндәү, дин сабагы укыту тыелган совет чорында дин нигезләрен укытуга җөрьәт итә. Билгеле, аңа кадәр дә яшеренеп кенә дингә укыту барган, әмма нәкъ Габделхак остаз тырышлыгы белән укыту шәхси ысулдан төркем ысулына күчә. 1960 еллар уртасында Г.Каюмов теләүчеләрне төркемнәргә туплап, укыта башлый.

Ул үзен дин галиме дип санамады, әмма үзе белгәнне башкаларга өйрәтү методикасын камиллеккә җиткереп, әсбаплар булдырып, бөтен булмышын мөгаллимлеккә багышлады. Күпчелек уку-укыту материалларын, үз кулы белән плакатлар ясап, файдалана торган булды. Гыйлем эстәү нияте белән килгән кешегә аларның ишекләре һәрвакыт ачык иде. Һәм шәкертләренең белем алуларын дәвам итүләрен, мәдрәсәләрдә укуларын кайгыртты. Габдулла Галиуллин, Госман Исхаков, Җәлил Фазлыев, Рәхимулла Яруллин, Басыйр Бикбаев, Габдерәшит Закиров, Әхмәт Сабиров, Камил Вәлиуллин, Рөстәм Вәлиуллин, Габделхәмит Зиннәтуллин, Рамил Зарипов һ.б. – барысы да заманында Габделхак хәлфә мәктәбен узучылар.

Шунысы мөһим: Габделхак абый гарәп имлясы белән укытуны җәдит галимнәре әзерләгән дәреслекләрдән алып барды. Аның тәэсирендә халкыбызда җәдит ысулы табигый төстә таралды. Һәм Габделхак остаз методикасы күп мәдрәсәләрдә әлегә хәтле кулланыла. Ул гомеренең ахырына кадәр безнең мәхәллә әһеле булды, мәдрәсә хәлләре белән кызыксынып торды. Белем йортыбыз яңа урынга күчкәч, ул беренче уку көнендә үк килеп, шәкертләрне котлады.

Габделхак хәзрәтне ишетеп кенә түгел, күреп тә белдем. Ул мәдрәсәбезгә даими килеп, шәкертләргә сәдакалар китереп, магнитофон тасмасына язылган вәгазьләрне тыңлатып, бүләк итеп һәм укулары белән кызыксынучы юмартларның берсе иде.

Г.Каюмов бик сирәк очрый торган кешеләр рәтенә керә. Ул үзендә динебез хуплаган бөтен хәерле сыйфатларны җыярга тырышкан шәхес булды. Шәригать хөкемнәренә ул ниндидер абстракт схема дип түгел, ә үзенә кагылышлы дип кабул итте. Аның кыяфәтеннән, үз-үзен тотышыннан ук Исламның тынычлык, хәерлелек дине икәнлеген аңларга була иде. Әдәпле сөйләшүе, пөхтә киенүе, гайбәткә катнашмавы һ.б. – безгә үрнәк алырлык сыйфатлар. Аңардан кешеләргә уңай тәэсирләр генә күчә иде. Аның үрнәге бүген дә зур тәрбияви өлге булып тора. Габделхак абый мисалы күрсәтә ки, бездәге шартларда исламча яшәргә бик мөмкин һәм үзеңне кеше буларак шәргый идеалга якынлаштыру да – хәл итәрлек мәсьәлә. Габделхак абый үзендә динебезнең рухилыгын сеңдергән, аны үрнәк дәрәҗәсендә калыплаган, әмма моңа ул халыктан бизү, мәгарәгә качу бәрабәренә түгел, ә киресенчә, халыкка ачык булуы, халыкны агартуга тырышуы аркасында иреште. Динне тотуда халкыбызга хас урталыкны саклады".

**Татарстанның Баш казые, Балтач районы имам-мөхтәсибе, Борбаш авылы мәчете имам-хатыйбы Җәлил хәзрәт Фазлыев:**

"...Габделхак абый һәр аваз, һәр иҗек, һәр тыныш билгесе җиренә җитсен дип тырыша иде. Йөзләгән шәкертләр белән шулай итеп шөгыльләнү өчен күпме сабырлык, күпме көч кирәк! Мин аларда ун елдан артык шәкерт булдым. Шундый остаз насыйп иткән өчен, Аллаһ Раббыбызга чиксез шөкераналар кылам.

35 ел бергә гомер иткән җәмәгате Нәҗия апа белән намаз укучы иманлы яшьләрне үзара таныштыру, кавыштыру өчен дә күп тырышлык куйдылар. Алар ярдәме белән унлап мөселман гаиләсе корылды. Мин аларда вакытта кайберәүләр "Габделхак абый, килен өчен бик зур рәхмәт", яисә "Кияү өчен зур рәхмәт" – дип әйтеп китәләр иде. Авылга кайтса, су буйларында йөрергә, урманга барырга ярата иде. Бик тә кызыксынучан иде ул. Күпләр аның оста бакчачы булуын да хәтерли. Авылга кайтса, күп кешенең бакчасына кереп алмагачларның, чияләрнең ботакларын кисеп, тәртипләп чыга иде.

Ул бер мәчеттә дә имам булып тормады, мәдрәсәдә мөгаллим булып эшләмәде. Әмма үз артыннан йөзләгән шәкерт тәрбияләп калдырды. Мин бу очракта тәрбияләү дигән сүзгә басым ясыйм. Бүген шәкертләрне укытабыз дип сөйлибез. Шәкерт белемле булудан бигрәк, тәрбияле булырга тиеш. Ә бу мәсьәләдә әле безгә остазларыбыздан бик күп өйрәнәсе бар".

**Нәҗия абыстай Каюмова, 35 ел бергә гомер иткән җәмәгате:**

"...1967 елдан башлап 1997 елның апреленә кадәр дин сабагы алырга теләүчеләр җыелган саен, һәр атнада Арчага йөреп сабак бирдек. Ә Казанда кечерәк төркемнәрне чиратлап төрле урында укыттык. 2-3 ел – Рәшидә абыстай Исхакыйларда. Бер ел җиен балалар җыелды. Рәшидә абыстайлар сараенда аларны

укытуны Тәлгатькә (Таҗетдин) кушты. Ике атна укыткан өчен, Габделхак яшь мөгаллимгә магнитофон бүләк итте. Тәлгать Вәлиуллиннар өендә берничә кыш укыттык. Балалары каникулларда безгә килеп укыйлар иде. 1968 елны бер бүлмәле фатир алдык. Биредә күп укыттык. 10-15әр кеше укып китүгә, икенчеләре килә иде. Дин тотуга рөхсәт чыккач, Габделхак Мәрҗанидә, Әҗемдә, Иске Таш мәчетендә, 1998 елдан Нагорный мәчетендә укытты. Арча, Балтач һәм Кукмара районнары авылларына йөрү гадәтебезгә керде. Туган авылы Ядегәргә дә (Кукмара районы) атна саен укытырга кайтып йөрдек".

**Заһит Каюмов, энесе:**

"Туган авылыбыз Ядегәрдә узган гасыр башында указлы мулла булып торган Таҗетдин бабабыз салдырган мәчет урынында 1994 елның 2 нче декабрендә җомга көнне күмәк көч белән мәчет ачылды. Абый канатланып йөрде инде: ничек булдыра ала – шулай тырышты, даими төстә матди ярдәм күрсәтте, оештыру эшләрен башлап йөрде, манарага ай эшләтеп алып кайтты. Мәчет ачылганда Коръән китаплары, үзенең бихисап методик әсбапларын бүләк итте. Һәм гомере буена туган авылыбызга, мәчеткә кайтып йөрде, китаплар, мөселман календарьлары бүләк итте.

2006 елны – абыебыз Габделхакның тууына 85 ел тулганда – авыл халкы мәчеткә "Габделхак" исеме бирү тәкъдиме белән чыкты. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтендә Г.Каюмовны искә алу мәҗлесе узды. Гаиләләребез белән барып, абый ядкәрен барладык. Вәлиулла хәзрәт Ягъкуб оештырган "Иман" нәшрияты абыйны белүче замандашларының хәтер-хатирәләрен туплап, "Остазларның остазы" дигән китап чыгарды. Абыйның тууына 90, 95 һәм 100 ел тулу уңаеннан гаиләбез стена календаре чыгарып таратты. Туган якка, хөрмәтле абыебыз исемен йөрткән мәчеткә сукмак өзелми.

2015-2016 елларда Габделхак абый уллары Зөфәр белән Рәшит энекәшләр мәчеттә капиталь ремонт ясаттылар. Манарадагы айны да алыштырырга туры килде. Компрессорлар заводында тутыкмас металлдан эшләнгән айны үз кулларым белән алып кайтып куйдырдым.

Мәчеткә исем бирү – бер эш. Аны әледән-әле халык күңелендә искә төшереп торуны, истәлекләр яңартуны мактаулы вазифабыз дип саныйбыз. Үсеп килүче ядегәрлеләргә Габделхак Каюмовның кем булуын, нинди эз калдыруын аңлатуны гаиләбез белән теләп башкарабыз.

Авылдашларыма дини китаплар, календарьлар, газеталар кайтарып торам. Кукмара төбәгенә багышланган "Алар илгә җиңү алып кайтты" дигән өстәмә ике томны табып, мәчеткә алып кайтып тапшырдым. Мәчет янындагы мәдрәсәдә дин сабагы алырга йөрүчеләргә уку-язу әсбаплары алып кайткалыйм. Быел март аенда мөгаллим, бик күпләргә туры юлны табарга булышкан абыебызның гаять зур мирасын, бай тәҗрибәсен барлаячакбыз. Г. Каюмовның тууына 100 ел тулу уңаеннан, "Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә "Габделхак остаз" укулары, ә Ядегәр авылы мәчетендә юбилей кичәсе белән искә алачакбыз".

**Зөфәр Каюмов, олы улы:**

"...Аллаһыга шөкер, әтиебезнең туган ягында мирасы онытылмый. Әтиебез исемен йөрткән мәчетне 2015 елда энем Рәшит гаиләсе, улым Рөстәм гаиләсе белән бергәләп эчтән-тыштан рәтләдек, заманча төс керттек. Мәчеткә өстәп янкорма төзелде. Ул хәзер дүрт авылга мәдрәсә булды. Мәдрәсәгә дә манара куйдык, авыл халкы аңа Фаиз хәзрәт Якупов исемен бирде. Мәчет-мәдрәсә ишек алдын матурлауны ландшафт дизайнерларыннан эшләттек, мәчеткә йөрүчеләргә уңайлыклар булдырдык, юлларны асфальтлап, машина куяр урыннар әзерләдек.

2017 елның 25 нче мартында Ядегәр урта мәктәбендә мәктәп директоры Илфат Әхмәдуллин тырышлыгы белән Габделхак Каюмов исемендәге I Республика-күләм "Эзләнүләр аша – камиллеккә" дип аталган фәнни-гамәли укулар узды. Өч ел рәттән уздырылган бу чарада Татарстан мәктәпләре укучылары фәнни-гамәли хезмәтләре белән катнаштылар. Ә без анда әтиебез Габделхак остаз мирасын җентекләп өйрәнгән иң тырышларга бүләкләр тапшырдык.




Әле күптән түгел генә авыл янындагы Бакыр чишмәсеннән мәчет янына ук торбалар сузып, авыл уртасына чишмә суы китерелде, суның химик составын тикшерттек. Авыл халкы хәзер рәхмәтләр укып, якыннан су ала. Мәктәптә авыл тарихына багышлап музей ачуда, аңа элеккеге мәчет белән бәйле кызыклы экспонатлар табышуда өлешебезне керттек. Кышын хоккей мәйданчыгында бик теләп яшьләр алка тибә. Капкачыларга ике спорт костюмы, спорт кирәк-ярагы алып бирдек.

Бөек Җиңүнең 75 еллыгы уңаеннан якын-тирәдәге 4 авылның Бөек Ватан сугышында һәлак булган һәм сугышта катнашкан фронтовиклар исемлеге язылган обелискны яңарттык, тирә-ягын төзекләндердек. Хәтер сагында торып һәм әтиебез башлаган игелек-хәйрия эшчәнлеген дәвам итеп, авылдашларыбыз күңелендә югалмас, онытылмас эз калдырасыбыз килә. Мәчеткә дә, авыл җирлегенә булышуны да изге бурычыбыз дип саныйбыз".

■ Ветеран-журналист
**Вәсилә РӘХИМОВА** язмасы

**Редакциядән**

***Кадерле укучыларыбыз!***

***"Үрнәк затлар" сәхифәсендә ислам дөньясында зур эз калдырган бөек затларыбыз белән таныштыруны дәвам итәбез. Сезнең төбәктә дә шундый кешеләр барлыгына ышанабыз һәм алар белән безнең укучыларыбызны да таныштыруыгызны телибез. Хатларыгызны газетабызның*** *marketing@huzur.ru* ***электрон почта адресына юллый аласыз.***

# Кайнар диңгез юлы

*(Повестьтән өзек)*

*(Дәвамы. Башы алдагы санда)*

Сургут шәһәре тарихында беренче тапкыр Сабантуйда азан әйтелде. Яшүсмер малай саф, чиста тавыш белән азан әйтә башлагач, халык шым булды. Берберсенә: “Кем улы бу малай?” – дигән сораулы карашлар сирпелде. Нәсыйха апа хатын-кызларга, Рәис Латыйпов ир-атларга таба борылып, азан әйтүченең шәһәрнең имамы Таһир хәзрәтнең ун яшьлек улы Камил әйткәнен җиткерде. Сүз җил кебек мәйданга таралды.

– Шәһәребезнең имамы Таһир хәзрәт Саматовны барыгыз да танып, күреп калыгыз. Барлык дини эшләр аның җитәкчелегендә башкарылачак, – диде хакимият башлыгы һәм сүзне хәзрәтнең үзенә бирде.

Рәйсә дулкынланудан, иренең барлык сүзләрен ишетеп тә бетерә алмады. Аны таныш булмаган апалар әйләндереп алды.

– Таһир хәзрәтнең абыстае икәнсез, танышыйк, – дип кулларын суздылар.

– Мин – Әлфия апаң, Зәйтүнә, Нурдидә, ирем Нурислам абыең...

Рәйсәнең алар белән күрешкәндә, сөенеченнән күзеннән яшенә кадәр бәреп чыкты, һәрберсенең кулына корбан ите тоттырды.

– Таһир хәзрәткә бергәләп булышыйк, ямегез, апаларым, – дип кенә әйтә алды.

– Дин бит ул, абыстай, барыбыз өчен дә яшәү ачкычы, – диде арадан берсе.

...Икенче көнне иртән үк Таһир, мәхәллә төзергә Устав эшләтү өчен, Ханты-Манси округына китте. Рәйсә улын җитәкләп, шәһәр белән танышты. Сургут шәһәрендә зур корылмалар төзелеп кенә килә. Мәчет кайсы ягында булыр икән?

– Әни! – диде Камил.

– Әү, балам.

– Бу матур шәһәр түгел, Казанда гына яшик. Мин монда укымыйм.

– Алай әйтергә ярамый, улым. Иртәгә Казанга кайтабыз. Әтиең фатир алгач, монда күченеп киләбез.

Әтиеңне ялгыз гына яшәтеп булмый ич, – дип җавап биргәч, Камил эндәшмәде.

* * *

...Санаулы көн тиз узды. Ире, фатир бирделәр, дип хәбәр итүгә, Рәйсә иң кирәкле әйберләрен тартмаларга тутырды. Гаиләсен алырга Таһир машина белән кайтты. Ике бала белән ике мең чакрым машинада авыр булыр дип, Рәйсә поезд белән барды.

...Ике ай эчендә Таһир хәзрәтнең гаиләсенә фатир да бирелгән, Камилне – мәктәпкә, Әлфинурны бакчага урнаштырырга да сөйләшенгән булуы, аларның тормышын җанландырып җибәрде. Беренче сентябрь көнне Камилне мәктәпкә илттеләр. Бигрәк тә укытучысының татар булуына куандылар. Әлфинурны бакчага ияләштерү генә әлегә авыр Рәйсәгә. Көн саен: “Казанга кайтыйк, дусларымны сагындым”, – дип елый. Бакчадан кайтканда, күршедә яшәүче балаларның велосипедта йөргәннәрен күргәч: “Миңа да сәпит кирәк”, – диде. Балага: “Акчабыз юк бит әле, кызым”, – дисә дә, Рәйсә Таһир белән киңәште. Дөресрәге, велосипед алып биргәч, Казанны сагынуы басылмасмы дип өметләнде. Шул кичне аларга Рәис Латыйпов килде. Кыз велосипед сорый дигәч, бурычка акча биреп торды. Әлфинурга сәпит алып биргәч, сагынып елавы кимеде...

...Судья хатыны Фәния аларны Коръән мәҗлесенә чакырып килгәндә, Рәйсә камыр ризыгы пешерә иде. Үзләре янына табынга чакырды. Өстәлгә куярга кабартма белән шикәрдән башка ризык юк.

– Булганы белән җитешегез, әлегә кибеттән тәм-том сатып алырлык мөмкинлек юк. Казаннан алып килгән оныбыз бар, көн саен диярлек тәмлүшкәләр пешерәм.

Фәния кабартманы мактыймактый, Рәйсә ясап биргән чәйне эчеп куйды. Янәшәсендә утырган Әлфинурның чәченнән сыйпап, хәлен сорашты. Бер катлы сабый, күңелендәгесен әйтеп салды.

– Көн саен кабартма да кабартма. Казанда кәнфит тә бар иде. Монда уйнарга уенчыгым да юк, – диде, авызын турсайтып.

– Иртәгә безгә мәҗлескә син дә кил яме, уенчыклар бирермен, – диде Фәния.

Мәҗлескә дүртесе бергә бардылар. Таһир хәзрәт йортка Коръән укыды. Мәҗлестән соң да кунакларның хәзрәтне табын янынан җибәрәселәре килмәде. Ипләп кенә үзләренең сорауларын бирделәр.

– Ханты-Манси округында юлларың уңдымы, хәзрәт?

– Мәхәлләнең Уставын алу авыр булмадымы?

Мәҗлестәгеләрнең дини эшчәнлек белән кызыксынулары хәзрәтнең күңелен күтәрде.

– Аллага шөкер, бик авырлык белән булса да, мәхәлләбезне теркәтеп, Уставын алып кайттык. Профсоюз комитеты рәисе Рәис Латыйпов белән өч көн көрәштек руслар белән. “Монда дини оешма нәрсәгә кирәк? Без ирекле дәүләттә яшибез, мөселманнар дигән аерым оешма төзү кирәк түгел”, – дип каршы төште юстиция җитәкчесе Козлов. Татар юристларына, татар судьясына аңлатып, бик авырлык белән алдык Уставны. Рәискә Аллаһның рәхмәте булсын, аның дуслары ярдәм итте. Кунакханәләр тулы, кунып чыгарга урын юк. Өч көн пароход каютасында йокладык. Әлхәмдүлилләһи, бу эшебезне башкардык. Хәзер безнең алда мәчет салу бурычы тора, кардәшләрем. Халыкка йөрергә уңайлы булсын өчен, урынны шәһәрнең уртасыннан алырга иде.

– Сургутта җир күп, булыр, хәзрәт. Мәхәллә составындагы җитәкчеләр булышырлар.

– Аллаһка һәм җитәкчеләрнең миһербанлы күңеленә ышанам да инде.

Мәҗлестәгеләр, үзләренчә ярдәм итәргә теләп, мәчет салу өчен уңайлы урыннар тәкъдим иттеләр. Кайдан биреләчәге әле Аллаһ кулында иде...

Саматовлар гаиләсен, Фәния белән ире фатирларына кадәр озата килделәр. Өстәлгә күп итеп азык-төлек куйдылар, Әлфинурга бер капчык йомшак уенчык бирделәр.

– Безнең балалар үсте инде, рәхәтләнеп уйна, матурым, – диде аңа Фәния.

* * *

Рәйсә ире белән көн саен төнге тәһәҗҗуд намазы укып, Аллаһтан мөселманнарны җыеп намаз укырлык урын сорап ялвардылар. Таһир хәзрәт иртүк тора да Сургут шәһәре баш идарәсе җитәкчесе янына бара. Җитәкчеләр яныннан нинди кәеф белән кайтуын, аның йөзенә карауга белә. Таһир авыр сулап, өстәл янына килеп утырды.

– Указлы мулла да булдым, Устав та бар. Тик бернинди үзгәреш юк, бу торгынлык кайчанга кадәр дәвам итәчәк? Мәчет төзер өчен, иң начар урыннарны тәкъдим итәләр. Вакытлыча гына гыйбадәт кыла торган бер бүлмә генә бирсәләр дә ярар иде.

– Хәмит Ясәвиев дигән җитәкче чакырды диде ич әткәй, барып кара әле аның янына, ул бит татар кешесе, сине аңламый калмас, – диде Рәйсә.

– Кем янына бара дип уйлыйсың соң син, Хәмит абый янына барам. Кабул итү бүлмәсендә басып торам, күтәрелеп тә карамыйча кабинетына кереп китә. Иртәгә соңгы тапкыр барып карыйм да, әгәр дә шушындый битарафлык дәвам итсә, кайтып китәбез Казанга, – диде төшенке тавыш белән. Казаннан килгән запас акчалар бетеп, күп көнне нәфел уразалары тотып көн уздырсалар да, булганына шөкер иттеләр.

...Рәйсә иренең йокламыйча таң аттырганын күрде. Таһир әле бер якка, әле икенче якка әйләнеп ятты. Җиде тулганчы өйдән чыгып киткән иде, сәгать тугызлар тирәсендә ярсыган хәлдә әйләнеп тә кайтты.

– Китәбез! Монда без кирәк түгел! – дип, урынга барып капланды.

Рәйсә ире янына барып утырды, кулы белән аркасыннан сыйпап алды.

– Нәрсә дип әйтте соң ул? Кайтып китәр дәрәҗәгә җиткерерлек, нинди сүз ул?

– Минем яныма көн саен килеп, аптыратып йөрмә, диде. Бу – син монда кирәк түгел, дигән җавапны аңлата түгелме соң? Китәбез, җаным, балаларны юлга әзерлә!

Рәйсә урыныннан кузгалып китмәде, җайлап кына үз сүзен әйтте.

– Минем дә Казанда яшисем килә, җаныем. Тик икенче ягы бар: сине булдыра алмады, шуның өчен кайтты, диячәкләр. Әткәй өчен бигрәк тә бик авыр булачак. Кайтмыйбыз, Таһир. Сургутта җитәкчеләр күп, башкаларына мөрәҗәгать итеп кара.

Таһир әкрен генә тынычланырга тырышты. Шулчак аларга заводта эшләүче Мөхтәр Сәгыйтов килеп керде. Дингә битараф булмаган бу кешене аларга, әйтерсең лә, Аллаһ Үзе җибәрде. Исәнлексаулык сорашып, йортка дога кылгач, Мөхтәр ярдәмен тәкъдим итте.

■ **Гөлсинә ГАЛИМУЛЛИНА**

(Дәвамы киләсе санда)

### ДҮШӘМБЕ

07:00 «Хәерле сәгатьтә»
08:00 «Хәдис дәресләре»
08:20 «Бәрәкәтле гаилә»
09:10 «Сүз эчендә хикмәт бар»
09:20 «Бер мәчет тарихы»
09:30 «Һөнәрләр»
09:45 «Барбаросса» мультфильмы
10:00 «Җилкәй» мультфильмы
10:15 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
10:40 «Тәмле булсын»
11:00, 20:00 «Хәзинә»
11:20 «Иң гүзәл исемнәр»
11:30 «МИМ»
11:40 «Намазга өйрәник»
12:00 Азан
12:05 «Учимся совершать намаз» (ир-атлар өчен)
12:25 «Разговоры о важном»
12:35 «Самые прекрасные имена»
12:45 «Барбаросса» мультфильмы
13:00 «Ветерок» мультфильмы
13:15 «Голос разума»
13:45 «Поучительные истории»
14:00 «Золотой век исламской цивилизации»
14:10 «Хузур-вояж» с Антоном Кротовым
14:30 Фәнни-танып белү фильмы
15:00, 00:00 Нәфис сериал «Пророк Юсуф»
16:00 «Хәерле сәгатьтә»
17:00 «Хәдис дәресләре»
17:20 «Бәрәкәтле гаилә»
18:10 «Сүз эчендә хикмәт бар»
18:20 «Бер мәчет тарихы»
18:30 «Һөнәрләр»
18:45 «Барбаросса» мультфильмы
19:00 «Җилкәй» мультфильмы
19:15 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
19:40 «Тәмле булсын»
20:20 «Иң гүзәл исемнәр»
20:30 «МИМ»
20:40 «Намазга өйрәник»
21:00 «Сказки снов» – нәниләр өчен программа
21:10 «Ветерок» мультфильмы
21:25 «Барбаросса» мультфильмы
21:40 «Голос разума»
22:10 «Золотой век исламской цивилизации»
22:20 «Разговоры о важном»
22:30 «Самые прекрасные имена»
22:40 «Поучительные истории»
23:00 «Учимся совершать намаз» (ир-атлар өчен)
23:20 «Хузур-вояж» с Антоном Кротовым
23:30 Фәнни-танып белү фильмы
01:00 Коръәни Кәрим укылышы

### СИШӘМБЕ

07:00 «Хәерле сәгатьтә»
08:00 «Тәфсир дәресләре. Тимергали Юлдашев»
08:30 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин
08:45 «Иң гүзәл исемнәр»
08:55 «Сүз эчендә хикмәт бар»
09:05 «Тәмле булсын»
09:25 «Балам-багалмам»
09:45 «Гаилә дәресләре»
10:15 «Хикмәтле хикәяләр»
10:25 «Барбаросса» мультфильмы
10:40 «Җилкәй» мультфильмы
10:55 «Бер хәдис – бер җавап»
11:05 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
11:30 «Рисәлә» Каюм Насыйри
11:40 «Намазга өйрәник»
12:00 Азан
12:05 «Уроки тафсира (мөфти Камил Сәмигуллин)»
12:30 «Ислам без стереотипов»
12:45 «Барбаросса» мультфильмы
13:00 «Ветерок» мультфильмы
13:15 «Исламские финансы»
13:35 «Момент истины» Али Абдусалимов белән
13:50 «Есть вопрос – есть хадис»
14:10 «Учимся совершать намаз»
14:30 Фәнни-танып белү фильмы
15:00, 00:00 Нәфис сериал «Пророк Юсуф»
16:00 «Хәерле сәгатьтә»
17:00 «Тәфсир дәресләре. Тимергали Юлдашев»
17:30 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин
17:45 «Иң гүзәл исемнәр»
17:55 «Сүз эчендә хикмәт бар»
18:05 «Тәмле булсын»
18:25 «Балам-багалмам»
18:45 «Гаилә дәресләре»
19:15 «Хикмәтле хикәяләр»
19:25 «Барбаросса» мультфильмы
19:40 «Җилкәй» мультфильмы
19:55 «Бер хәдис – бер җавап»
20:05 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
20:30 «Рисәлә» Каюм Насыйри
20:40 «Намазга өйрәник»
21:00 «Сказки снов» – нәниләр өчен программа
21:10 «Ветерок» мультфильмы
21:25 «Барбаросса» мультфильмы
21:40 «Исламские финансы»
22:00 «Уроки тафсира (мөфти Камил Сәмигуллин)»
22:25 «Ислам без стереотипов»
22:40 «Учимся совершать намаз»
23:00 «Есть вопрос – есть хадис»
23:20 «Золотой век исламской цивилизации»
23:30 Фәнни-танып белү фильмы
01:00 Коръәни Кәрим укылышы

### ЧӘРШӘМБЕ

07:00 «Хәерле сәгатьтә»
08:00 «Хәдис дәресләре»
08:20 «Бәрәкәтле гаилә»
09:10 «Сүз эчендә хикмәт бар»
09:20 «Бер мәчет тарихы»
09:30 «Һөнәрләр»
09:45 «Барбаросса» мультфильмы
10:00 «Җилкәй» мультфильмы
10:15 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
10:40 «Тәмле булсын»
11:00, 20:00 «Хәзинә»
11:20 «Иң гүзәл исемнәр»
11:30 «МИМ»
11:40 «Намазга өйрәник»
12:00 Азан
12:05 «Учимся совершать намаз» (ир-атлар өчен)
12:25 «Разговоры о важном»
12:35 «Самые прекрасные имена»
12:45 «Барбаросса» мультфильмы
13:00 «Ветерок» мультфильмы
13:15 «Голос разума»
13:45 «Поучительные истории»
14:00 «Золотой век исламской цивилизации»
14:10 «Хузур-вояж» с Антоном Кротовым»
14:30 Фәнни-танып белү фильмы
15:00, 00:00 Нәфис сериал «Пророк Юсуф»
16:00 «Хәерле сәгатьтә»
17:00 «Хәдис дәресләре»
17:20 «Бәрәкәтле гаилә»
18:10 «Сүз эчендә хикмәт бар»
18:20 «Бер мәчет тарихы»
18:30 «Һөнәрләр»
18:45 «Барбаросса» мультфильмы
19:00 «Җилкәй» мультфильмы
19:15 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
19:40 «Тәмле булсын»
20:20 «Иң гүзәл исемнәр»
20:30 «МИМ»
20:40 «Намазга өйрәник»
21:00 «Сказки снов» – нәниләр өчен программа
21:10 «Ветерок» мультфильмы
21:25 «Барбаросса» мультфильмы
21:40 «Голос разума»
22:10 «Золотой век исламской цивилизации»
22:20 «Разговоры о важном»
22:30 «Самые прекрасные имена»
22:40 «Поучительные истории»
23:00 «Учимся совершать намаз» (ир-атлар өчен)
23:20 «Хузур-вояж» с Антоном Кротовым
23:30 Фәнни-танып белү фильмы
01:00 Коръәни Кәрим укылышы

### ПӘНҖЕШӘМБЕ

07:00 «Хәерле сәгатьтә»
08:00 «Тәфсир дәресләре. Тимергали Юлдашев»
08:30 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин
08:45 «Иң гүзәл исемнәр»
08:55 «Сүз эчендә хикмәт бар»
09:05 «Тәмле булсын»
09:25 «Балам-багалмам»
09:45 «Гаилә дәресләре»
10:15 «Хикмәтле хикәяләр»
10:25 «Барбаросса» мультфильмы
10:40 «Җилкәй» мультфильмы
10:55 «Бер хәдис – бер җавап»
11:05 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
11:30 «Рисәлә» Каюм Насыйри
11:40 «Намазга өйрәник»
12:00 Азан
12:05 «Уроки тафсира (мөфти Камил Сәмигуллин)»
12:30 «Ислам без стереотипов»
12:45 «Барбаросса» мультфильмы
13:00 «Ветерок» мультфильмы
13:15 «Халяль-лайфстайл»
13:35 «Момент истины» Али Абдусалимов белән
13:50 «Есть вопрос – есть хадис»
14:10 «Учимся совершать намаз»
14:30 Фәнни-танып белү фильмы
15:00, 00:00 Нәфис сериал «Пророк Юсуф»
16:00 «Хәерле сәгатьтә»
17:00 «Тәфсир дәресләре. Тимергали Юлдашев»
17:30 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин
17:45 «Иң гүзәл исемнәр»
17:55 «Сүз эчендә хикмәт бар»
18:05 «Тәмле булсын»
18:25 «Балам-багалмам»
18:45 «Гаилә дәресләре»
19:15 «Хикмәтле хикәяләр»
19:25 «Барбаросса» мультфильмы
19:40 «Җилкәй» мультфильмы
19:55 «Бер хәдис – бер җавап»
20:05 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
20:30 «Рисәлә» Каюм Насыйри
20:40 «Намазга өйрәник»
21:00 «Сказки снов» – нәниләр өчен программа
21:10 «Ветерок» мультфильмы
21:25 «Барбаросса» мультфильмы
21:40 «Халяль-лайфстайл»
22:00 «Уроки тафсира (мөфти Камил Сәмигуллин)»
22:25 «Ислам без стереотипов»
22:40 «Учимся совершать намаз»
23:00 «Есть вопрос – есть хадис»
23:20 «Золотой век исламской цивилизации»
23:30 Фәнни-танып белү фильмы
01:00 Коръәни Кәрим укылышы

### ҖОМГА

07:00 «Хәерле сәгатьтә»
08:00 «Хәдис дәресләре»
08:20 «Бәрәкәтле гаилә»
09:10 «Сүз эчендә хикмәт бар»
09:20 «Бер мәчет тарихы»
09:30 «Һөнәрләр»
09:45 «Барбаросса» мультфильмы
10:00 «Җилкәй» мультфильмы
10:15 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
10:40 «Тәмле булсын»
11:00, 20:00 «Хәзинә»
11:20 «Иң гүзәл исемнәр»
11:30 «Минбар»
12:00 Азан
12:05 «Учимся совершать намаз» (ир-атлар өчен)
12:25 «Разговоры о важном»
12:35 «Самые прекрасные имена»
12:45 «Барбаросса» мультфильмы
13:00 «Ветерок» мультфильмы
13:15 «Голос разума»
13:45 Поучительные истории
14:00 «Золотой век исламской цивилизации»
14:10 «Хузур-вояж» с Антоном Кротовым»
14:30 Фәнни-танып белү фильмы
15:00, 00:00 Нәфис фильм «Пророк Юсуф»
16:00 «Хәерле сәгатьтә»
17:00 «Хәдис дәресләре»
17:20 «Бәрәкәтле гаилә»
18:10 «Сүз эчендә хикмәт бар»
18:20 «Бер мәчет тарихы»
18:30 «Һөнәрләр»
18:45 «Барбаросса» мультфильмы
19:00 «Җилкәй» мультфильмы
19:15 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
19:40 «Тәмле булсын»
20:20 «Иң гүзәл исемнәр»
20:30 «Минбар»
21:00 «Сказки снов» – нәниләр өчен программа
21:10 «Ветерок» мультфильмы
21:25 «Барбаросса» мультфильмы
21:40 «Голос разума»
22:10 «Золотой век исламской цивилизации»
22:20 «Разговоры о важном»
22:30 «Самые прекрасные имена»
22:40 «Поучительные истории»
23:00 «Учимся совершать намаз» (ир-атлар өчен)
23:20 «Хузур-вояж» с Антоном Кротовым
23:30 Фәнни-танып белү фильмы
01:00 Коръәни Кәрим укылышы

### ШИМБӘ

07:00 «Хәерле сәгатьтә»
08:00 «Тәфсир дәресләре. Тимергали Юлдашев»
08:30 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин
08:45 «Иң гүзәл исемнәр»
08:55 «Сүз эчендә хикмәт бар»
09:05 «Тәмле булсын»
09:25 «Балам-багалмам»
09:45 «Гаилә дәресләре»
10:15 «Хикмәтле хикәяләр»
10:25 «Барбаросса» мультфильмы
10:40 «Җилкәй» мультфильмы
10:55 «Бер хәдис – бер җавап»
11:05 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
11:30 «Рисәлә» Каюм Насыйри
11:40 «Намазга өйрәник»
12:00 Азан
12:05 «Уроки тафсира (Камил Сәмигуллин)»
12:30 «Ислам без стереотипов»
12:45 «Барбаросса» мультфильмы
13:00 «Ветерок» мультфильмы
13:15 «Халяль-лайфстайл»
13:35 «Момент истины» Али Абдусалимов белән
13:50 «Есть вопрос – есть хадис»
14:10 «Учимся совершать намаз»
14:30 Фәнни-танып белү фильмы
15:00, 00.00 Нәфис фильм «Пророк Юсуф»
16:00 «Хәерле сәгатьтә»
17:00 «Тәфсир дәресләре. Тимергали Юлдашев»
17:30 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин
17:45 «Иң гүзәл исемнәр»
17:55 «Сүз эчендә хикмәт бар»
18:05 «Тәмле булсын»
18:25 «Балам-багалмам»
18:45 «Гаилә дәресләре»
19:15 «Хикмәтле хикәяләр»
19:25 «Барбаросса» мультфильмы
19:40 «Җилкәй» мультфильмы
19:55 «Бер хәдис – бер җавап»
20:05 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
20:30 «Рисәлә» Каюм Насыйри
20:40 «Намазга өйрәник»
21:00 «Сказки снов» – нәниләр өчен программа
21:10 «Ветерок» мультфильмы
21:25 «Барбаросса» мультфильмы
21:40 «Исламские финансы»
22:00 «Уроки тафсира (мөфти Камил Сәмигуллин)»
22:25 «Ислам без стереотипов»
22:40 «Учимся совершать намаз»
23:00 «Есть вопрос – есть хадис»
23:20 «Золотой век исламской цивилизации»
23:30 Фәнни-танып белү фильмы
01:05 Коръәни Кәрим укылышы

### ЯКШӘМБЕ

07:00 «Хәерле сәгатьтә»
08:00 «Хәдис дәресләре»
08:20 «Бәрәкәтле гаилә»
09:10 «Сүз эчендә хикмәт бар»
09:20 «Бер мәчет тарихы»
09:30 «Һөнәрләр»
09:45 «Барбаросса» мультфильмы
10:00 «Җилкәй» мультфильмы
10:15 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
10:40 «Тәмле булсын»
11:00, 20:00 «Хәзинә»
11:20 «Иң гүзәл исемнәр»
11:30 «Минбар»
12:00 Азан
12:05 «Учимся совершать намаз»
12:25 «Разговоры о важном»
12:35 «Самые прекрасные имена»
12:45 «Барбаросса» мультфильмы
13:00 «Ветерок» мультфильмы
13:15 «Актуальный ислам» Камил Сәмигуллин
13:35 Маленькие взрослые
13:45 «Поучительные истории»
14:00 «Золотой век исламской цивилизации»
14:10 «Хузур-вояж» с Антоном Кротовым»
14:30 Фәнни-танып белү фильмы
15:00, 00.00 Нәфис фильм «Пророк Юсуф»
16:00 «Хәерле сәгатьтә»
17:00 «Хәдис дәресләре»
17:20 «Бәрәкәтле гаилә»
18:10 «Сүз эчендә хикмәт бар»
18:20 «Бер мәчет тарихы»
18:30 «Һөнәрләр»
18:45 «Барбаросса» мультфильмы
19:00 «Җилкәй» мультфильмы
19:15 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
19:40 «Тәмле булсын»
20:20 «Иң гүзәл исемнәр»
20:30 «Минбар»
21:00 «Сказки снов» – нәниләр өчен программа
21:10 «Ветерок» мультфильмы
21:25 «Барбаросса» мультфильмы
21:40 «Актуальный ислам» Камилем Самигуллин
22:00 «Маленькие взрослые»
22:10 «Золотой век исламской цивилизации»
22:20 «Разговоры о важном»
22:30 «Самые прекрасные имена»
22:40 «Поучительные истории»
23:00 «Учимся совершать намаз» (ир-атлар өчен)
23:20 «Хузур-вояж» с Антоном Кротовым
23:30 Фәнни-танып белү фильмы
01:00 Коръәни Кәрим укылышы

# Казан өчен февраль аена намаз вакытлары

| Көн | Көн Исеме | Иртәнге намаз | | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы/ ифтар | Ясту намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | |
| 01.02.2021 | Дүш | 05:28 | 06:07 | 07:37 | 12:00 | 14:26 | 16:17 | 18:04 |
| 02.02.2021 | Сиш | 05:27 | 06:05 | 07:35 | 12:00 | 14:28 | 16:19 | 18:06 |
| 03.02.2021 | Чәрш | 05:25 | 06:03 | 07:33 | 12:00 | 14:30 | 16:22 | 18:08 |
| 04.02.2021 | Пәнҗ | 05:23 | 06:01 | 07:31 | 12:00 | 14:32 | 16:24 | 18:10 |
| 05.02.2021 | Җом | 05:22 | 05:59 | 07:29 | 12:00 | 14:34 | 16:26 | 18:12 |
| 06.02.2021 | Шим | 05:20 | 05:57 | 07:27 | 12:00 | 14:36 | 16:28 | 18:14 |
| 07.02.2021 | Якш | 05:18 | 05:55 | 07:25 | 12:00 | 14:38 | 16:30 | 18:15 |
| 08.02.2021 | Дүш | 05:17 | 05:53 | 07:23 | 12:00 | 14:40 | 16:32 | 18:17 |
| 09.02.2021 | Сиш | 05:15 | 05:51 | 07:21 | 12:00 | 14:42 | 16:35 | 18:19 |
| 10.02.2021 | Чәрш | 05:13 | 05:48 | 07:18 | 12:00 | 14:44 | 16:37 | 18:21 |
| 11.02.2021 | Пәнҗ | 05:11 | 05:46 | 07:16 | 12:00 | 14:46 | 16:39 | 18:23 |
| 12.02.2021 | Җом | 05:09 | 05:44 | 07:14 | 12:00 | 14:48 | 16:41 | 18:25 |
| 13.02.2021 | Шим | 05:07 | 05:42 | 07:12 | 12:00 | 14:50 | 16:43 | 18:27 |
| 14.02.2021 | Якш | 05:05 | 05:40 | 07:10 | 12:00 | 14:52 | 16:46 | 18:29 |
| 15.02.2021 | Дүш | 05:03 | 05:37 | 07:07 | 12:00 | 14:53 | 16:48 | 18:31 |
| 16.02.2021 | Сиш | 05:01 | 05:35 | 07:05 | 12:00 | 14:55 | 16:50 | 18:33 |
| 17.02.2021 | Чәрш | 04:59 | 05:33 | 07:03 | 12:00 | 14:57 | 16:52 | 18:35 |
| 18.02.2021 | Пәнҗ | 04:57 | 05:31 | 07:01 | 12:00 | 14:59 | 16:54 | 18:37 |
| 19.02.2021 | Җом | 04:55 | 05:28 | 06:58 | 12:00 | 15:01 | 16:56 | 18:39 |
| 20.02.2021 | Шим | 04:52 | 05:26 | 06:56 | 12:00 | 15:03 | 16:59 | 18:41 |
| 21.02.2021 | Якш | 04:50 | 05:23 | 06:53 | 12:00 | 15:05 | 17:01 | 18:43 |
| 22.02.2021 | Дүш | 04:48 | 05:21 | 06:51 | 12:00 | 15:07 | 17:03 | 18:45 |
| 23.02.2021 | Сиш | 04:46 | 05:19 | 06:49 | 12:00 | 15:09 | 17:05 | 18:47 |
| 24.02.2021 | Чәрш | 04:43 | 05:16 | 06:46 | 12:00 | 15:11 | 17:07 | 18:49 |
| 25.02.2021 | Пәнҗ | 04:41 | 05:14 | 06:44 | 12:00 | 15:13 | 17:09 | 18:51 |
| 26.02.2021 | Җом | 04:39 | 05:11 | 06:41 | 12:00 | 15:15 | 17:11 | 18:53 |
| 27.02.2021 | Шим | 04:36 | 05:09 | 06:39 | 12:00 | 15:17 | 17:13 | 18:55 |
| 28.02.2021 | Якш | 04:34 | 05:06 | 06:36 | 12:00 | 15:18 | 17:16 | 18:57 |

18 нче февральдән 19ына каршы төн - Рәгаиб кичәсе

ДИН вә МӘГЫЙШӘТ
*Гыйнвар саны, №1 (306)*

Баш мөхәррир: **Нәширбанов И.К.**
Мөхәррир: **Хамматов Л. Г.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сабирова Ф. И.**

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;
ТР МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе
**Булат МӨБАРӘКОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДһӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2531
Газетага ярты елга язылу бәясе – 170,04 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 26 нчы гыйнварда таратыла.
График буенча бу санга 25 нче гыйнвар көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.